Министерство образования и науки РФ
Казанский (Приволжский) федеральный университет
Институт психологии и образования

А.Н. Хузиахметов

# Педагогика: Введение в педагогическую деятельность

## Конспект лекций

Казань – 2013

**Хузиахметов А.Н.**

**Педагогика: Введение в педагогическую деятельность («Педагогика: Педагогика фәнен керешә») (курс на татарском языке): Конспект лекций** / Хузиахметов А.Н.; Казанский (Приволжский) федеральный университет. – Казань, 2013. – 88 с.

Содержание курса базируется на материале, освоенном ранее в курсах школьного обучения. В предлагаемых лекциях изучаются вопросы, которые раскрывают общую характеристику педагогической профессии, сущность и специфику педагогической деятельности, обосновываются требования к личности учителя, рассматривается профессиональная компетентность учителя.

Её освоение необходимо для формирования целостного представления студентов о педагогической науке и практике, обеспечивает успешное освоение педагогических дисциплин на последующих этапах обучения.

Электронная версия курса: http://bars.kpfu.ru/course/view.php?id=1614

Принято на заседании кафедры методологии обучения и воспитания
Протокол № 12 от 03.06.2013

**© Казанский федеральный университет**
**© Хузиахметов А.Н.**

**Направление: 050100.62 «Педагогическое образование»**
«Математика, информатика и информационные технологии в билингвальной тат.-рус. среде»

**Дисциплина: «Педагогика: Введение в педагогическую деятельность» («Педагогика: Педагогика фәненә кереш») (курс на татарском языке)**

**Количество часов:** 72 (в т.ч.: 18 ч. – лекции, 18 ч. – практические занятия, 36 ч. – самостоятельная работа), форма контроля: зачет.

**Темы:** 1. Педагогика фәненә кереш. Педагогика фәне һәм аның бурычлары. 2. Төп педагогик төшенчәләр. 3. Шәхес формалашу нигезләре. 4. Укытучы эшчәнлеген иҗади оештыру. 5. Педагогик хезмәттәшлекнең төп юнәлешләре. 6. Педагог хезмәтенең нәтиҗәлелеген билгеләү. 7. Мәгариф үсешенең төп үзенчәлекләре. 8. Укыту процессы һәм укытучы шәхесе. 9. Белем бирүнең эчтәлеген яңарту.

**Ключевые слова:** воспитание, образование, педагогическая профессия, система образования, педагогическая культура, педагогическая деятельность, педагогические знания, умения, навыки, профессиональное воспитание.

**Дата начала эксплуатации:** 1 сентября 2013 г.

**Автор-составитель:** Хузиахметов Анвар Нуриахметович, заведующий кафедрой методологии обучения и воспитания Института психологии и образования КФУ, доктор педагогических наук, профессор.

Размер: 782 Кб
Ссылка: http://libweb.ksu.ru/ebooks/20-IPO/20_221_kl-000574.pdf

## *ОГЛАВЛЕНИЕ*


*Тема 1. ПЕДАГОГИКА ФӘНЕНӘ КЕРЕШ. ПЕДАГОГИКА ФӘНЕ ҺӘМ АНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ* . 6
*1.1. Педагогика фәненә кереш* ... 6
*1.2. Педагогиканы өйрәнү нигә кирәк?* ... 7
*1.3. Фән буларак педагогиканың барлыкка килүе һәм үсеше* ... 13
*1.4. Педагогиканың мөһим бурычлары* ... 17
*1.5. Вопросы для самоконтроля* ... 18
*1.6. Задания для практики* ... 18
*1.7. Глоссарий по теме 1* ... 19
*1.8. Использованные информационные ресурсы* ... 19
*Тема 2. ТӨП ПЕДАГОГИК ТӨШЕНЧӘЛӘР* ... 20
*2.1. Төп педагогик төшенчәләр* ... 20
*2.2. Фәнни-педагогик тикшеренү методлары* ... 22
*2.3. Вопросы для самоконтроля* ... 28
*2.4. Глоссарий по теме 2* ... 28
*2.5. Использованные информационные ресурсы* ... 28
*Тема 3. Шәхес формалашу нигезләре* ... 29
*3.1. Кешенең үсешендә нәселдәнлекнең роле* ... 29
*3.2. Кешенең үсешендә һәм шәхес формалашуда әйләнә-тирә мохитнең роле* ... 32
*3.3. Кешенең үсешендә һәм шәхес буларак формалашуында тәрбиянең роле* ... 33
*3.4. Вопросы для самоконтроля* ... 35
*3.5. Задания для практики* ... 35
*3.6.Глоссарий по теме 3* ... 35
*3.7. Использованные информационные ресурсы* ... 36
*Тема 4. Укытучы эшчәнлеген иҗади оештыру* ... 37
*4.1. Укытучы эшчәнлеген иҗади оештыру* ... 37
*4.2. Вопросы для самоконтроля* ... 44
*4.3. Задания для практики* ... 44
*4.4. Глоссарий по теме 4* ... 45
*4.5. Использованные информационные ресурсы* ... 45
*Тема 5. ПЕДАГОГИК ХЕЗМӘТТӘШЛЕКНЕҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ* ... 46
*5.1. Педагогик хезмәттәшлекнең төп юнәлешләре* ... 46
*5.2. Вопросы для самоконтроля* ... 53
*5.3. Задания для практики.* ... 53
*5.4. Глоссарий по теме 5* ... 53
*5.5. Использованные информационные ресурсы* ... 54
*Тема 6. ПЕДАГОГ ХЕЗМӘТЕНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БИЛГЕЛӘҮ* ... 55
*6.1. Педагог хезмәтенең нәтиҗәлелеген билгеләү* ... 55
*6.2. Вопросы для самоконтроля* ... 59
*6.3. Задания для практики* ... 59
*6.4. Глоссарий по теме 6* ... 60
*6.5. Использованные информационные ресурсы* ... 60
*Тема 7. МӘГАРИФ ҮСЕШЕНЕҢ ТӨП ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ* ... 61
*7.1. Мәгариф үсешенең төп үзенчәлекләре* ... 61
*7.2. Вопросы для самоконтроля* ... 66
*7.3. Задания для практики* ... 66
*7.4. Глоссарий по теме 7* ... 67
*7.5. Использованные информационные ресурсы* ... 67
*Тема 8. УКЫТУ ПРОЦЕССЫ ҺӘМ УКЫТУЧЫ ШӘХЕСЕ* ... 68
*8.1. Укыту процессы һәм укытучы шәхесе* ... 68
*8.2. Укыту процессында аралашу* ... 69
*8.3. Укытуда мохит йогынтысының роле* ... 70
*8.4. Укыту процессының структурасы* ... 70
*8.5. Укыту процессында укытучы эшчәнлеге* ... 72
*8.6. Вопросы для самоконтроля* ... 77

*8.7. Задания для практики* ........ 78
*8.8. Глоссарий по теме 8* ........ 78
*8.9. Использованные информационные ресурсы* ........ 78
*Тема 9. БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕН ЯҢАРТУ* ........ 80
*9.1. Белем бирүнең эчтәлеген яңарту* ........ 80
*9.2. Вопросы для самоконтроля* ........ 87
*9.3. Задания для практики* ........ 87
*9.4. Глоссарий по теме 9* ........ 87
*9.5. Использованные информационные ресурсы* ........ 88

# Тема 1. ПЕДАГОГИКА ФӘНЕНӘ КЕРЕШ. ПЕДАГОГИКА ФӘНЕ ҺӘМ АНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

**Аннотация.** Данная тема раскрывает понятие педагогики, возникновения и развития педагогики. Рассматривается педагогика как наука и основные задачи.

**Ключевые слова.** Педагогика, наука, педагогическая деятельность, личность.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

## 1.1. Педагогика фәненә кереш

**Педагогика** – кешегә тәрбия бирү турындагы фән. Педагогика грекча *paidagogos – балалар җитәкчесе* дигән сүздән алынган. Борынгы Грециядә балаларны мәктәпкә алып бару, алып кайту һәм карау эше тапшырылган кешеләрне *педагоглар* дигәннәр. Соңрак тәрбиячеләрне, укытучыларны педагог дип атый башлаганнар. Аларның эше *педагогик эшчәнлек* дип исемләнә башлаган.

**Педагогика** – тәрбия бирүнең максат һәм бурычлары, эчтәлеге, алымнары һәм аны оештыру турындагы тәгълимат ул. Икенче төрле әйткәндә, үсеп килүче яшь буынны нинди эшләр башкарырга әзерләргә, аларда нинди сыйфатлар булдырырга, аларны нәрсәгә һәм ничек өйрәтергә, ничек тәрбияләргә дигән сорауларга педагогика җавап бирә.

Педагогиканың предметы, җәмгыятьнең махсус функциясе буларак, кеше тәрбияләү. Башкача әйткәндә, педагогиканың предметы булып укыту һәм тәрбия эшчәнлеге тора.

Кешелек җәмгыяте үсеше тарихында яшь буынны тәрбияләүгә һәркайчан зур игътибар бирелгән. Җәмгыять әле иҗтимагый сыйныфларга бүленмәгән, кеше өстеннән кеше хакимлек итү булмаган чакта өлкәннәр яшь буынга тәҗрибәләрен турыдан-туры эш процессында тапшыра торган булганнар. Ул чор тәрбиясендә аңлылыкка караганда стихиялелек күбрәк күзәтелгән. Ләкин, җәмгыять үсә барган саен, тәрбия эше дә максатчанрак була алган.

Үсеп килүче яшь буынны тәрбияләү тәҗрибәсе туплана барган, акрынлап махсус тәрбия йортлары барлыкка килгән, тәрбия һәм укыту эше белән махсус шөгыльләнүче кешеләр килеп чыккан. Булган тәҗрибәнең мәгънәсенә төшенү, аны гомумиләштерү зарурлыгы туган. Шулай итеп, кешелек җәмгыяте ихтыяҗларыннан мәктәп барлыкка килә, үсеп килүче яшь буынны тәрбияләү һәм аңа белем бирү турындагы фән – педагогика туа. Педагогика тәрбия бирүнең максатлары һәм бурычлары, эчтәлеге, методлары һәм оештырылуы турындагы тәгълиматны эченә ала.

## 1.2. Педагогиканы өйрәнү нигә кирәк?

Шундый сорау туа: педагогиканы белмичә дә балаларына яхшы тәрбия биргән кешеләр азмыни? Яки, киресенчә, педагогиканы яхшы белүчеләрнең хәтта үз балаларына да начар тәрбия бирү очраклары юкмыни? Җавап болай: беренчеләре, педагогиканы белгән очракта, балаларын тагын да яхшырак тәрбияләгән булырлар иде. Ә икенчеләренең балаларын начар тәрбияләве бу эштә педагогика ярдәм итә алмаганлыктан түгел, бәлки аларның үз белемнәрен практикада кулланмауларыннан килә.

Педагогиканы теоретик яктан да, практик яктан да өйрәнергә кирәк, ягъни тәрбия бирү юнәлешенә һәм тәрбия чаралары системасына яхшы төшенергә генә түгел, бәлки бу белемнәрне эштә куллана белергә дә, балаларга дөрес һәм уңышлы тәрбия бирергә дә өйрәнү кирәк. Педагогика фәнен белү нигезендә тәрбияләү сәнгатен, ягъни педагогика эше осталыгын үзләштерә барырга кирәк.

Мәгълүм ки, хәтта бик талантлы кеше дә белем һәм осталыкларын камилләштерү өстендә күп эшләгәндә генә гүзәл нәтиҗәләргә ирешә. Педагогик

белем һәм, осталыклар педагогның хезмәтен камилләштерә, ялгышлардан саклап кала. Тәрбиячеләрнең педагогик белемнәре булмауның балаларга никадәр зарар китерүе сер түгел бит.

Тәрбия өлкәсендәге ялгышларны төзәтү бик кыен була. Алар балаларның әхлакый һәм физик гарипләнүләренә китерә. Педагогик белемнәре булмаган тәрбиячеләр, кайчакта, ихтыярсыздан, балаларда кимчелекләр артуга сәбәпче булалар, аларның уңышларын һәм талантларын томалап калдыралар, сәләтләрен үстерергә ирек бирмиләр.

Олуг фикер ияләренең бик күбесе тикмәгә генә педагогиканы гомуми белем фәне дип санамый, чөнки тормышта һәр кеше теге яки бу күләмдә бала тәрбияләү белән шөгыльләнә.

Педагогик эшчәнлекне һөнәр итеп сайлаган кешегә инде педагогиканы белү бигрәк тә кирәк. Педагогик белемсез кеше мәктәпкә килсә, эшкә ничек керешеп китәргә дә белмәячәк. Эше нәтиҗәле булсын өчен, аңа тәрбиянең максатын һәм бурычларын ачык белү зарур. Бары шунда гына аның эшендә тиешле дәрәҗәдә максатка омтылучанлык туачак.

Булачак укытучы тәрбия эшендә баланы нәрсәгә өйрәтергә, балалар коллективын ничек оештырырга, ал арны нинди чаралар белән өйрәтергә һәм тәрбияләргә кирәген яхшы белергә тиеш.

Педагогика фәне менә шуларга җавап бирә дә инде.

Тәрбия эше кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле яши, дидек. Тәрбия балаларның бер-берсенә һәм өлкәннәргә мөнәсәбәтенә, ал арның уен хәрәкәтләренә, хезмәткә, тулаем бөтен җәмгыятькә карашларына юнәлеш биреп килгән. *Тәрбия – иҗтимагый күренеш.* Ләкин гомуми җәмгыять булмаганлыктан, (ягъни борынгы җәмгыять, колбиләүчелек җәмгыяте, феодаль җәмгыять булган), гомуми тәрбия дә юк. Хаким сыйныфлар тәрбия аша үз сәясәтләрен, үсеп килә торган яшь буынга үз йогынтыларын үткәрәләр.

Бер иҗтимагый стройны икенчесе белән алыштыру революцион юл белән эшләнә һәм, строй үзгәрү белән бергә, тәрбия бирүнең эчтәлеге, аны оештыру формалары һәм методлары да үзгәрә. Тәрбия бирү практикасы һәм теориясе

тигез, эзлекле үзгәрми, бәлки иҗтимагый, сыйнфый көрәштә үзгәрә. Димәк, педагогика – тарихи фән ул.

Борынгы җәмгыятьтә сыйныфлар булмаган. Балалар бертөрле тәрбия алганнар, һәм бу тәрбия турыдан-туры хезмәт процессында, шулай ук балаларның уеннарында тормышка ашырылган. Ләкин, хезмәтнең җенескә карап бүленүе сәбәпле, ир һәм кыз балаларны тәрбияләүдә беркадәр аерма булган. Мәсәлән, ир балалар – аучылыкка, кызлар торак тирәсендәге эш төрләренә өйрәтелгәннәр.

Борынгы җәмгыятьтә үк инде, гәрчә махсус тәрбия бирү йортлары булмаса да, өлкәннәрнең тәҗрибәсен махсус рәвештә яшь буынга тапшыру белән шөгыльләнүчеләр булган. Җәмгыять тәрбия эшен контрольдә тоткан, аны оештырган һәм аңа тиешле юнәлеш биргән. Димәк, ул чорда ук инде тәрбия эше саф стихияле процесс кына булмаган.

Җәмгыять сыйныфларга бүленә башлагач, бай балаларын тәрбияләү ярлы балаларын тәрбияләүдән кискен аерыла. Мәсәлән, борынгы колбиләүчелек дәүләте Спартада бары хаким сыйныф балалары гына дәүләт исәбенә тәрбияләнгәннәр.

Спарталылар үз балаларын хәрби хакимлеккә әзерләгәннәр. Шуңа күрә спарталыларда төп укыту предметы гимнастика һәм хәрби эш булган. Балаларда үз дәүләтенә ихлас бирелгәнлек, сугышчанлык, батырлык, тәртип, җитезлек, чыдамлык, тыйнаклык, колларга җирәнеп карау һ.б.ш. сыйфатлар үстерергә омтылганнар.

Егетләрне хәрби лагерьларга җибәргәннәр, алар анда чыныгу алганнар. Физик тәрбиягә зур игътибар бирү белән беррәттән музыкага, җыр һәм биюгә өйрәткәннәр.

Өлкәннәргә һәм идарәчеләргә һичсүзсез буйсыну, колларга, физик хезмәткә җирәнеп карау – Спартада хакимлек иткән изүче сыйныф балалары әнә шул рухта тәрбияләнгәннәр. Кол һәм "ирекле" дип йөртелгән гади халык балалары мәктәпләрдә яки башка төрле уку йортларында укымаганнар, һөнәрчеләр гаиләләрендә һәм турыдан-туры җир хуҗаларында эшләгәннәр,

физик хезмәткә өйрәнгәннәр, хуҗаларына буйсынучанлык рухында тәрбияләнгәннәр.

Безнең эрага кадәр VII - V гасырларда Афинада икътисади шартлар Спартага караганда үзгәрәк булган. Биредә сәүдә шактый үскән. Идарәчеләр белән халык арасында хакимият өчен көрәш барган. Гәрчә биредә дә колбиләүчелек хуҗалыгы булып, азсанлы "гражданнар" йөз меңнәрчә коллар өстеннән хакимлек итсәләр дә, Афинада балаларга тәрбия бирү гимнастика, хәрби эш һәм хәрби музыка белән генә чикләнә алмаган инде. Колбиләүчеләр балаларының белем алулары, киң күләмдә сәүдә итү һәм сәяси тормышта актив катнашу өчен кирәкле сыйфатларга ия булулары белән кызыксынганнар.

Ул заманда Афина халкының шактый зур өлеше сәяси көрәшкә тартылган. Урамнарга, мәйданнарга җыелган халыкка хәрби көч белән генә түгел, бәлки оратор сүзе белән дә йогынты ясау кирәк булган. Шунлыктан Афинада хәрби сәнгать белән беррәттән ораторлык сәнгате дә бик югары бәяләнгән. Байларның уллары 7 яшьтән 17 яшькә кадәр түләүле хосусый мәктәпләргә йөргәннәр. Анда алар үз-үзләрен тоту кагыйдәләренә, дөрес язарга, санарга, әдәби сүз сөйләргә, шулай ук җыр, поэзия һәм гимнастикага өйрәнгәннәр. Афинаның җир биләүче сәүдәгәрләре улларына физик һәм хәрби тәрбия биргәннәр. Яшь буын сәяси, фәлсәфи әңгәмәләр алып барган, сөйләү осталыгына ия булган. Аеруча байлар бик күп акча түләп бу сәнгатькә аерым "софист" укытучылардан өйрәнгәннәр. Грек фәлсәфәчесе Платон әйтүенчә, Афина яшьләре шулай белем алганнар, игенчеләр һәм һөнәрчеләр белән идарә итәргә өйрәнгәннәр.

Шулай итеп, антик колбиләүчелек җәмгыятендә колбиләүчеләр сыйныфы тарафыннан юнәлеш бирелә торган тәрбия шул сыйныфның хакимлеген ныгытуга һәм изелүчеләр сыйныфын буйсындыруга юнәлдерелгән.

Хаким сыйныф балалары заманына күрә киң белем алганнар. Ә кол балалары фәннәрдән һәм сәнгатьтән бөтенләй читтә кала килгәннәр, аларны мәктәпкә алмаганнар.

Коллар революциясе колбиләүчелек җәмгыятен җимерә, аңа алмашка феодаль җәмгыять килә.

Төрле иҗтимагый төркемнәрнең таркаулыгы, үз эченә бикләнгәнлеге, чиркәү йогынтысының гаять дәрәҗәдә үсүе, аерым феодалларның үзара өзлексез көрәшүләре сәбәпле тәрбия бирүнең максатлары антик җәмгыятьтәгедән аерыла. Башка феодалларга һәм крестьяннарга каршы көрәшү өчен рыцарьга сөңге, кылыч белән эш итәргә, атта йөрергә һ.б. өйрәнергә кирәк була. Аңарда шул сыйфатларны тәрбиялиләр дә. Рыцарьга фәнни белем кирәк булмаган диярлек. Шуңа күрә, кагыйдә буларак, дөньяви феодаллар бөтенләй диярлек укый-яза белмәгәннәр, фән яки физик хезмәт белән шөгыльләнүчеләргә җирәнеп караганнар.

Урта гасыр җәмгыяте тормышында бик зур роль уйнаган руханилар, хакимлекләрен һәм йогынтыларын ныгыту өчен, халыкка "теге дөньядагы тормыш" хакына түзәргә кирәк, бары "теге дөнья" гына – чын дөнья, дип аңлатырга тырышканнар. Чиркәүгә, феодалга буйсыну, хис-теләкләрен тыю, үз фикере булмау, авырлыкларга сыкранмыйча түзү – тәрбияләнүче алдына куела торган таләпләр әнә шулар булган. Дин хакыйкатьнең бердәнбер чыганагы булып саналган. Ләкин дини хакыйкатьләр чынбарлыкны белүгә түгел, ә гадәттән тыш көчләргә, "Алланың җир йөзендәге вәкиле" абруена нигезләнгән. Чиркәүгә тулысынча, сукырларча баш ию һәм һичсүзсез буйсыну, дөньяви фәнне дошман күрү әнә шуннан килә. Фән дингә хезмәт иткән. Чын фәнни фикер каты җәзага дучар ителгән, чиркәү җәлладлары тарафыннан күп кенә галимнәрнең башлары киселгән.

Урта гасырларда крестьяннар үзләрен коллыкка төшергән дөньяви һәм рухани феодаллар тарафыннан бик каты изелгәннәр. Белем алу ягыннан бөтенләй караңгылыкта кала килгәннәр.

Феодаль җәмгыятьтә тәрбия эше катлаулана дияргә була. Дворяннарның үз эченә бикләнгән катлавын тәшкил итүче (дворянлык мирас итеп тапшырыла) дөньяви феодаллар чиркәү һәм монастырь мәктәпләрендә фән белән шөгыльләнүне түбән эш дип санаганнар. Кайбер эре феодал сарайларында югары катлау балалары өчен үз мәктәпләре ачылса да, алар бик аз булган. Соңыннан дворян балалары өчен өстенлекле мәктәпләр – ир балалар өчен хәрби

һәм дөньяви уку йортлары, кызлар өчен махсус институтлар ачылган. Бу уку йортларына түбән катлау балалары алынмаган.

Руханилар аерым катлау булганнар. Шулай ук крестьяннар, һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр дә үз эченә бикләнгән катлау төркемнәрен тәшкил иткәннәр. Бу төркемнәрдән чыгу аерата нык чикләнгән.

Урта гасырларда феодаль җәмгыятьтә чиркәү һәм монастырь мәктәпләре күп булган. Әмма ул мәктәпләрдә бирелә торган белемнәр тормыш белән бәйләнмәгән, аларда әйберләрнең үзләрен өйрәнү белән түгел, бәлки һәртөрле ясалма билгеләмәләр, төшенчәләрне телдән өйрәнү белән генә шөгыльләнгәннәр. Шуның белән бергә аларда бөтен нәрсә тамгалар белән, дини мәгънәдә аңлатылган.

Яңа педагогикага нигез салучы, "Бөек дидактика" авторы Ян Амос Коменскийның әлеге "схоластик сафсата"га карашы менә нинди булган: "Бер елда төшенә алырдай нәрсәләр белән укучыларны биш, ун һәм аннан да күбрәк ел тоткарлаганнар. Аңга акрынлап кертә барырга мөмкин нәрсәләрне көчләп такканнар, укучыларның башына тукып, дыңгычлап керткәннәр. Үзең күреп һәм аермачык күз алдына китереп була торган нәрсәне, караңгы, буталчык итеп, табышмак кебек чуалтып аңлатканнар..." Укучыларның башларын күбесенчә "...чүп-чар сүзләр, мәгънәсез лыгырдау, фикер калдыклары һәм сөрем белән тутырганнар".

Шулай итеп, феодаль җәмгыятьтә дә тәрбия эше сыйнфый характерда булган. Биредә белем бирү, нигездә, чиркәү һәм руханилар кулында булганга күрә, дини рухта, тормыштан аерылган, күп сүзле, үтә схоластик булган.

Буржуазия иске феодаль җәмгыятькә каршы аяусыз көрәш алып бара, атап әйткәндә, феодаль җәмгыятьтәге тәрбиянең катлаулылыгына кискен каршы чыга, белем бирү өлкәсендә тигез хокуклылык таләп итә. Бу ул вакытта, һичшиксез, алдынгы таләп иде.

Буржуаз педагогика феодализмга каршы көрәш чорында күп кенә прогрессив таләпләрне алга сөрде. Балаларга схоластик, тормыштан аерылган белем бирү урынына, мәктәпне тормыш белән бәйләү, балаларның яшь

үзенчәлекләрен исәпкә алу, белем бирүдә күрсәтмәлелек куллану һәм укучыларга гуманлы мөнәсәбәт таләп ителде. Ир һәм кыз балалар өчен гомуми укыту программасы кертү турындагы мәсьәлә куелды. Белем бирүне элеккегә караганда шактый тизләтергә, өстәвенә күбрәк балаларны укытырга мөмкинлек бирә торган яңа форма һәм методлар эшләнде.

XVIII гасыр уртасында ул чорның иң зур педагогик фикер ияләреннән берсе Жан-Жак Руссо кеше хокукларын һәм шәхеснең ирекле үсешен бик нык яклап чыкты. "Табигый тәрбия бирү" идеясен алга сөреп, кешеләр ирекле, сәләтле булып туалар, ә җәмгыять аларны боза, чөнки тәрбия учреждениеләре социаль тигезсезлек һәм изү рухы белән сугарылган. Табигый хәлдә генә кешеләр арасында фактик тигезлек яши һәм кешене кеше тарафыннан коллыкка төшерү булмый, дигән караштан чыгып эш итте. Шуңа күрә Руссо тәрбия эшен бозык җәмгыятьтән читтә алып барырга, аны җәмгыятькә бәйсез (ирекле) итәргә кирәк дип санады.

Руссоның карашы, үз вакыты өчен алдынгы булса да, аның төп идеясе тормышка аша алмый иде.

### 1.3. Фән буларак педагогиканың барлыкка килүе һәм үсеше

Һәр фәннең үз тарихы була. Аның теоретик нигезләренә төшенү һәм аларны үзләштерү өчен әлеге тарихны белүнең әһәмияте зур. Шуның өчен педагогика курсын өйрәтүне аның үсеше турында кыскача гына тарихи күзәтүдән башлап китәргә кирәк.

Педагогика – борынгы белем тармакларының берсе, һәм ул асылда җәмгыять үсеше белән аерылгысыз.

Бу фикер аңлашыла төшсен өчен, бер җитди нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Педагогик белемнәр кеше эшчәнлегенең тәрбиягә бәйле үзенчәлекле даирәсенә карый. Чынлап та, педагогика турында сөйләгәндә, гадәттә, бу сүз тәрбия төшенчәсе белән тәңгәлләшә. Ә тәрбия эше кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле яши. Хезмәт коралларын ясауга һәм табигать хәзинәсен үзләштерүгә бәйле җитештерү тәҗрибәсен, шулай ук хезмәттәшлек һәм күмәк

эшчәнлек тәҗрибәсен туплап, кешеләр бу тәҗрибәне яшь буынга биреп калдырырга тырышканнар. Кешеләрнең һәр буыны ата-бабалар тәҗрибәсен баетып һәм тагын да камилләштереп үзеннән соң килгән буыннарга тапшыруы нәтиҗәсендә иҗтимагый үсеш мөмкин була. Шулай итеп, туплана килгән җитештерү тәҗрибәсен, әхлакый һәм социаль тәҗрибәне яшь буынга тапшыру – кешелек җәмгыятенең яшәеше һәм үсеше өчен мөһим алшарт һәм аның төп вазифаларыннан берсе. Менә шуңа күрә тәрбия эше кешелек җәмгыятенең барлыкка килүе һәм үсеше белән аерылгысыз.

Башка иҗтимагый күренешләр кебек үк, тәрбия бирү эшчәнлеге һәм аның сыйфаты да бер көе генә тормый, җәмгыятьтәге шартлар йогынтысында даими камилләшә, үсә. Бик борынгы заманнарда өлкәннәр белән күмәк хезмәт эшчәнлегендә һәм көндәлек аралашу нәтиҗәсендә балалар җитештерү һәм әхлак тәҗрибәсе туплаганнар.

Ыруглык җәмгыяте урнашканга кадәр һәм ыруглар яшәгән чорда, әле тәҗрибә үзе дә чагыштырмача гади булган заманнарда да шулай була. Бу чорда тәрбия эше аерым бер иҗтимагый бурыч буларак аерылып тормый һәм кешеләрнең һөнәри эшчәнлегенең махсус өлкәсен тәшкил итми, ягъни балалар өчен махсус тәрбия учреждениеләре дә, педагогик эшчәнлек белән махсус шөгыльләнүче һәм бала тәрбияләүне һөнәр иткән кешеләр дә булмый. Бу хәл колбиләүчелек чорында да озак саклана.

Кешелек җәмгыяте үсешенең билгеле бер баскычында, аерым алганда колбиләүчелек строеның соңгырак чорында, җитештерү һәм фән шактый үсеш алгач, тәрбия эше иҗтимагый вазифа буларак аерылып чыга, ягъни махсус тәрбия бирү учреждениеләре, балаларны өйрәтүче һәм аларга тәрбия бирүче кешеләр барлыкка килә. Бу күп кенә илләрдә шулай була, әмма малайлар өчен ачылган мәктәпләр турындагы азмы-күпме мәгълүматлар безгә Якын Көнчыгыш илләреннән һәм Борынгы Грециядән килеп җиткән.

Педагогик фикерләү теориясе башлангычларын фәлсәфә нигезләреннән эзләргә кирәк, чөнки ул – борынгы заманнардан ук тормышның мәгънәсе, кеше

яшәешенең максатлары, җәмгыятьтәге роле һәм урыны, кешене тормышта үз урынын табарга әзерләү турындагы сорауларга җавап эзләүче фән.

Фәлсәфи фикерләү колбиләүчелек җәмгыятендә үк шактый үсеш ала. Төзек фәлсәфи система **Сократ** (безнең эрага кадәр 469 – 399 еллар), **Платон** (б. э. га кадәр 427 – 347 еллар), **Аристотель** (б.э. га кадәр 384 – 322 еллар), **Демокрит** (б. э. га кадәр 460 – 370 еллар) кебек борынгы фикер ияләре тарафыннан тудырыла. Аларның фәлсәфи тәгълиматында кеше тәрбияләү, шәхес формалаштыру, аның тормыштагы урынын билгеләү мәсьәләләренә бәйле идея һәм принциплар бар.

Борынгы заман педагогикасы дингә бәйле: яхшы һәм яман турындагы дини күзаллаулар бәян ителгән, гаилә һәм җәмгыять әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрнең аерым нормалары билгеләнгән изге китаплардан үзенчәлекле педагогик васыятьләр, тәртип кагыйдәләре – кешеләр турында, ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләр турында күрсәтмәләр табарга була.

Тәрбия һәм белем бирү мәсьәләләре күп кенә фикер ияләре, язучылар, галимнәрнең игътибарын – гәрчә аларның кайберләре тәрбия эшчәнлеге белән турыдан-туры шөгыльләнмәсәләр дә – үзенә даими җәлеп итеп килгән. Яңарыш чоры язучылары һәм фикер ияләре **Витторино да Фельтре** (1378 – 1446), **Ф. Рабле** (1494 – 1553), инглиз фәлсәфәсече **Дж. Локк** (1632 – 1704), XVIII гасыр француз мәгърифәтчесе **Ж.-Ж. Руссо** (1712 – 1778), педагогика фәне теоретиклары **К.А. Гельвеций** (1715 – 1771), **Д. Дидро** (1713 – 1784) һәм башкалар бала табигате, тәрбиянең максаты, юллары һәм чаралары турындагы якты уй-фикерләре белән педагогик фикерләү үсешенә йогынты ясадылар.

Педагогиканы фәннең гаять мөһим тармагы буларак рәсмиләштерү чех педагогы **Ян Амос Коменский** (1592 – 1670) исеменә бәйле. Аның "Олуг дидактика" исемле зур хезмәте хаклы рәвештә беренче фәнни педагогика китабы дип исәпләнә.

Педагогик фикерләү үсешендә һәм педагогиканың фән буларак формалашуында күренекле Швейцария педагогы **И.Г. Песталоцци** (1746 –

1827) һәм немец педагогы **А. Дистервег** (1790 – 1866) хезмәтләре һәм педагогик эшчәнлек тәҗрибәләре зур әһәмияткә ия.

Педагогика теориясе үсешенә революциягә кадәрге Россиянең прогрессив педагоглары һәм мәгърифәтчеләре керткән казанышлар да зур. **Л.Н. Толстой** (1828 – 1910) крестьян балалары өчен мәктәп ача, күп кенә дәреслекләрне, шул исәптән мәшһүр "Азбука" һәм арифметика дәреслеген үзе яза, патша мәктәпләрендә хөкем сөргән хәрефкә ябышып ятуга һәм коры формализмга протест белдерә. Балаларның иҗади сәләтен үстерергә чакыра, һәр баланың шәхесен ихтирам итәргә өйрәтә. Танылган рус хирургы һәм либераль җәмәгать эшлеклесе **Н.И. Пирогов** (1810 – 1881) балаларны катлауларга аеручы мәктәпләрне кискен тәнкыйтьләп чыкты, баланы "кеше итеп үстерергә" тиешле тәрбия эшенә карашларны тамырдан үзгәртү кирәклеген яклады.

Педагогика фәне үсешенә **К.Д. Ушинский** (1824 – 1870) керткән өлеш аеруча зур.

Ушинскийның педагогик карашлары аның "Кеше – тәрбия җимеше" исемле бик мөһим хезмәтендә бәян ителгән. Ул карашлар шулай ук берничә буын балалар укып үскән, үзе төзегән уку китапларында, шул исәптән "Туган тел" һәм "Балалар дөньясы" китапларында гәүдәләнеш таба.

Танылган татар галиме, мәгърифәтче, педагог һәм язучы **Каюм Насыйри** (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров) (1825 – 1902) халыкчан тәрбия идеясен алга сөрә. Аның "Тәрбия китабы", "Әхлак рисаләсе", "Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре" хезмәтләрендә гуманистик татар халык педагогикасы турында гаять бай материал тупланган. Рус җәмәгатьчелеген татар халкының рухи мәдәнияте белән таныштыру максатыннан Каюм Насыйри күп кенә зирәк һәм хикмәтле сүзләрне русчага тәрҗемә итеп тә бирә.

Күренекле татар мәгърифәтчесе һәм язучысы **Галимҗан Ибраһимовның** (1887 – 1938) эшчәнлеге демократик педагогика формалашуга шактый йогынты ясады.

Галимҗан Ибраһимов гуманлы тәрбиянең күп кенә юнәлешләрен җентекләп эшләде. Бу җәһәттән аның "Тәрбия эшендә иреклелек һәм гуманлылык нигезләре" исемле хезмәте игътибарга лаек.

## 1.4. Педагогиканың мөһим бурычлары

Оешкан төстә алып барылган тәрбиягә озак еллар дәвамында балалар гына тартылып килде, һәм шуңа күрә педагогиканы *балаларга тәрбия бирү турындагы фән* дип атыйлар иде. Ә хәзер исә педагогиканы *кешене барлык үсеш баскычларында тәрбияләү турындагы фән* дип әйтәләр. Педагогиканы болай аңлату бик актуаль, чөнки хәзерге чорда белем бирүнең мәктәпкәчә учреждениеләрдән башлап гомуми белем бирү, һөнәри белем бирү һәм хезмәт ияләренең квалификациясен күтәрүнең күптөрле формаларына кадәр барлык буыннарын эченә алган тулы бер системасы булдырыла.

Укытучы булырга җыенган кеше тәрбия процессында баланы нинди баскычлардан алып барырга, аны нәрсәләргә өйрәтергә, балалар коллективын ничек оештырырга кирәклеген яхшы белергә, тирәнтен аңларга тиеш.

Бу сорауларга нәкъ менә педагогика фәне җавап бирә дә инде. Әлеге бурычларны белем бирү мәсьәләләрен кую һәм аның эчтәлеген, укыту-тәрбия эшләренең алымнарын билгеләү нигезендә педагогика хәл итә.

Хәзерге заманда фән һәм техниканың төрле тармакларында белемнәр күләме гадәттән тыш тиз үсә, шуңа күрә белем бирү, тәрбия, укыту эшендә элеккеге эчтәлек нигезендә, элекке алымнарны кулланып кына чордан калышмыйча алга бару кыенлаша.

Үсешләрнең төрле баскычында балалар һәм яшьләрнең нәрсәне үзләштерергә тиешлеген билгеләүдә педагогика өчен яңа критерийлар булдыру зарур. Яшь буынны үзлегеннән белем алу һәм үз-үзен тәрбияләү юллары һәм алымнары, мөстәкыйль фәнни эзләнүләргә, фәнни тикшеренүләргә тизрәк кереп китәргә булышырдай методлар белән коралландыру мәсьәләсе аеруча кискен тора.

Хәзерге катлаулы шартларда педагог осталыгына таләп арта бара. Бүгенге балалар элеккеге чор балаларыннан аерыла; тормышның төрле өлкәләрендәге хәлләр һәм вакыйгалар турында, техник һәм фәнни казанышлар, әдәбият-сәнгать әсәрләре һ.б. турында мәгълүмат бирүче каналлар күп булу сәбәпле, хәзерге балалар иртә өлгерәләр, аларның таләп һәм омтылышлары да җитдирәк була бара. Педагоглардан укучыларның танып белү, интеллектуаль һәм практик эшчәнлек активлыгын үстерүгә исәпләнгән метод һәм алымнар куллану таләп ителә. Педагогика укытучыларны үз эшенең остасы итәргә тиеш тә. Ул теоретик фән генә түгел, ә бәлки гамәли фән дә.

Алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнеп һәм гомумиләштереп, фәнни күзәтү һәм тәҗрибәләрдән файдаланып, педагогика белем, осталык һәм күнекмәләрне, үз-үзеңне тоту гадәтләрен үзләштерүдә, танып белү сәләтен һәм дөньяга карашларны үстерүдә ныклы нәтиҗәләр бирергә, белем һәм тәрбия ысулларын, аларны куллану шартларын табу һәм нигезләү мәсьәләсен хәл итәргә тиеш.

Хәзерге чорда яшь буынны тәрбияләүнең үзенчәлеге – бу эштә күп кенә көчләр: гаилә, иҗтимагый оешма һәм учреждениеләр катнашуында. Педагог алар белән хезмәттәшлек итә. Педагогиканың мөһим бурычы – бергәләп эшләү дәверендә төп җаваплылык педагог-белгечләр өстенә төшүен истә тотып, әлеге хезмәттәшлекнең эчтәлеге һәм алымнары, вазифаларны бүлешү һәм көчләрне берләштерү мәсьәләләрен хәл итү.

### 1.5. Вопросы для самоконтроля

1. Что изучает педагогика?
2. Каковы задачи педагогики?
2. Почему педагогику называют и наукой, и искуством?
4. Зачем педагогике познавать человека, его жизнь?

### 1.6. Задания для практики

1. Необходимо написать эссе на тему «Мой любимый учитель», «Учитель – мастер» или «Мой идеал учителя»

2. Ознакомиться с текстом документа «Тема 1», добавить вопросы для самоконтроля.

## 1.7. Глоссарий по теме 1

**Педагогическая деятельность** – это целенаправленное, специально организованное педагогическое взаимодействие, целью которого является создание условий для развития обучающегося и воспитывающегося.

**Профессия** – это особый род занятий, трудовой деятельности человека.

## 1.8. Использованные информационные ресурсы

http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор. РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php

## Тема 2. ТӨП ПЕДАГОГИК ТӨШЕНЧӘЛӘР

**Аннотация.** Данная тема раскрывает основные категории педагогики.

**Ключевые слова.** Образование, обучение, воспитание, личность, педагогический эксперимент.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### 2.1. Төп педагогик төшенчәләр

Педагогиканың категорияләре дип аталган төп төшенчәләренә үсеш, белем алу, уку, тәрбия (махсус һәм киң мәгънәсендә) керә.

**Кешенең үсеше** – идарә ителә һәм идарә ителми торган социаль һәм табигый факторларның тышкы һәм эчке йогынтысы астында шәхеснең формалашу процессы ул.

Шәхеснең үсешен **психик, физик** һәм **гомуми** үсешләргә аерып йөртәләр. Психик үсеш дигәндә шәхеснең аң-акыл (интеллект), ихтыяр, хис-тойгы үсеше, шулай ук аның ихтыяҗлары, сәләт һәм характер үсеше күздә тотыла. Физик үсеш исә – организмның, мускулларның, буыннар хәрәкәтчәнлегенең һ. б. үсеше ул. Гомуми үсеш – шәхеснең психик, физик, әхлакый һәм башка сыйфатлары үсеше.

**Белем алу** –укучыларда фәнни белемнәр һәм танып белү күнекмәләре, гадәтләр системасын булдыру, шулар нигезендә дөньяга караш, шәхеснең әхлакый һәм башка сыйфатларын формалаштыру, аның иҗади көчләрен һәм сәләтләрен үстерү процессы һәм нәтиҗәсе. Белем алу нигездә системалы укыту юлы белән тормышка ашырыла.

**Укыту** – укытучылар һәм укучыларның максатка юнәлдерелгән бердәм эшчәнлеге ул; кешегә белем бирү шул эшчәнлек аша тормышка ашырыла.

Махсус педагогик мәгънәсендә **тәрбия** – шәхеснең үсешенә, аның мөнәсәбәтләре, шәхси сыйфатлары, карашлары, иманына, җәмгыятьтә үз-үзен тотышына максатчан йогынты процессы һәм нәтиҗәсе.

Киң мәгънәсендә алганда **тәрбия** – максатчан укыту һәм тәрбия йогынтысында шәхеснең үсеш процессы һәм нәтиҗәсе.

**Шәхеснең формалашуы** – аның әйләнә-тирә мохит, нәселдәнлек һәм тәрбия йогынтысында үсеш процессы һәм нәтиҗәсе.

Педагогикадагы төп төшенчәләрнең билгеләмәләре үзләре үк аларның үзара тыгыз бәйләнгәнлеге һәм үзара керешүе турында сөйли. Шуңа күрә аларга характеристика биргәндә һәр төшенчәнең өстенлеген, төп функциясен күрә белү һәм нәкъ менә шул нигездә аны башка категорияләрдән аеру зарур.

Педагогикада "яшь буын" төшенчәсе еш кулланыла, ул аеруча "үсеп килүче" сүзе белән янәшә йөри, шулай ук буыннар бәгланышы, яңа буынга тәҗрибә тапшыру һәм башка төшенчәләр турында сүз алып барыла. Бер буын кешеләре дип якынча бер чорда туган кешеләргә әйтәләр. Социологлар буыннар чоры дип ата-аналары туган вакыттан алып аларның балалары туганга кадәр чорны исәплиләр, ә бу исә якынча утыз елга тигез.

Педагогикада күп кенә башка төшенчәләр дә кулланыла, алар педагогика курсының темаларын үткәндә каралачак.

Булачак укытучы фәнни педагогик төшенчәләрне белдергән сүзләрне бик төгәл кулланырга, аларның билгеләмәсе турында җентекләп уйланырга, тасвирланган күренешнең асылына төшенергә тиеш.

Тәрбиянең объекты – физик яктан һәм акыл ягыннан үсүче кеше. Аның үсеше гомер буе дәвам итә. Кеше физик һәм психик яктан, сыйфат һәм сан ягыннан төрле үзгәрешләр кичерә. Физик үзгәрешләргә сөяк һәм мускуллар системасының, эчке органнар, нерв системасының үсеше һәм ныгуы керә. Психик үзгәрешләргә барыннан элек акыл үсеше, шәхеснең психик яктан формалашуы һәм җәмгыятьтә яшәү өчен кирәк булган социаль сыйфатларны булдыру керә.

**Нәселдәнлек** дигәндә ата-аналары белән биологик охшашлыкның балаларында кабатлануы күздә тотыла. Нәселдәнлекне киңрәк тә аңларга була, ягъни аңа кеше биологик зат буларак туганда ата-анасыннан күчкән һәм кешенең генотибын билгеләгән бөтен генетик программасын һәм шулай ук ана карынында үсеш алган (тумыштан килгән) сыйфатларны да кертергә була.

**Әйләнә-тирә мохит** – шактый киң төшенчә, чөнки ул, гаиләдән һәм янәшә-тирәдәгеләрдән башлап, социаль тирәлекне, ягъни әлеге кеше дөньяга килгән һәм аңа үсү һәм тәрбияләнү өчен шартлар тудырган җәмгыятьне дә кертеп, баланың гомерлек тирәлеген үз эченә ала.

**Шәхес** төшенчәсе, "кеше" төшенчәсеннән аермалы буларак, кешенең социаль характеристикасын, ягъни аның башка кешеләр белән, гомумән, җәмгыять белән аралашуы һәм мөнәсәбәтләр урнаштыруы йогынтысында формалаша торган сыйфатларын билгели.

Баланың үсеше –катлаулы һәм каршылыклы процесс, аңа төп өч фактор – нәселдәнлек (эчке шартлар), әйләнә-тирә мохит һәм тәрбия (тышкы тәэсирләр) йогынты ясый.

Баланың үсешенә бу өч факторның йогынтысы турындагы мәсьәлә, аларның үзара нинди бәйләнештә торуы, әлеге сыйфатларның кайсысы һәм кайчан әйдәүче ролен үтәве бик зур фәнни һәм гамәли әһәмияткә ия.

## 2.2. Фәнни-педагогик тикшеренү методлары

**Фәнни-педагогик тикшеренү методлары** педагогика фәне үсешендә, аның тикшеренү алымнарының баюы һәм камилләшүендә мөһим фактор булып тора. Кайчандыр ул абстракт фәлсәфи-социологик фикерләргә генә нигезләнгән, ә педагогик идеяләр бөек фикер ияләренең иҗат нәтиҗәсе булган. Әмма XVII гасырдан башлап педагогика фәнен тәрбия эшендә теоретик эшчәнлекне практика белән бәйләп алып баруны алга сөргән галимнәр баета башлый.

XIX гасырда педагогикага укыту һәм тәрбия эшендәге тикшеренүләрнең эксперименталь алымнары кертелә башлый. Аларның педагогик теорияне

эшләүгә йогынтылары зур була. Хәзерге вакытта педагогик тикшеренүләр төрле методлары булган бөтен бер система ярдәмендә тормышка ашырыла. Аларга педагогик күзәтүләр, тикшеренү-әңгәмәләр методы, мәктәпнең эш кәгазьләрен һәм укучыларның эш нәтиҗәләрен өйрәнү, педагогик эксперимент, алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү һәм гомумиләштерү, социологик тикшеренү методлары (анкета тарату, рейтинг), математик статистика методлары, педагогик идеяләрне һәм күренешләрне теоретик анализлау һ. б. методлар керә. Педагогик проблемаларны монографик тикшеренү методы шактый нәтиҗәле була.

Әлеге методларның асылына кыскача гына тукталып китик.

**Педагогик күзәтүләр методы.** Бу метод нигездә теләсә нинди педагогик тикшеренүдә кулланыла, һәм бу табигый дә. Педагогик күренешләрне өйрәнү фәнни тикшеренүчедән аларны турыдан-туры туплауны, педагогик эшләргә туры килгән фактик материалларны теркәп баруны таләп итә. Мәсәлән, галим дәрескә кереп утыра һәм, укытучы материални кызык итеп сөйләп биргәндә, балаларның тыныч утыруларын, игътибар белән тыңлауларын күрә. Алга таба тикшеренүче дәресләрдә кайбер укучыларның актив катнашуын, укытучының сорауларына җавап бирергә тырышуын, иптәшләренең җавапларын тулыландыруын, дәреснең эчтәлегенә тирәнрәк төшенү өчен үзләренең дә сораулар бирүен һ. б. күрә. Кайберәүләре исә пассивлыклары белән аерылып торалар: укьггучы сорау биргәндә, һәрвакытта да җавап бирә алмыйлар. Әлеге фактларны күзәтү фәнни тикшеренүчегә, укучыларның игътибары күбесенчә дәреснең ни дәрәҗәдә эчтәлекле булуына бәйле, яхшы укучылар дәрестә зур активлык күрсәтәләр, дигән нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек бирә. Шулай итеп, күзәтүләр билгеле бер теоретик фикер йөртү, нәтиҗә чыгару өчен нигез була, соңыннан исә алар башка алымнар ярдәмендә тагын да тирәнрәк өйрәнүгә һәм тикшерүгә куела. Педагогик күзәтүләр методы тикшеренүчедән сабырлык һәм эзлеклелек таләп итә.

**Тикшеренү әңгәмәләре методы.** Бу метод ярдәмендә галим теге яки бу педагогик фактларга һәм күренешләргә карата тәрбиячеләрнең дә,

тәрбияләнүчеләрнең дә фикерен һәм мөнәсәбәтен ачыклый, шуның белән бу күренешләрнең асылы һәм сәбәпләре турында тирәнрәк күзаллау тупларга тырыша. Әгәр укучыларның дәрестә үзләрен төрлечә тотулары турындагы югарыда китерелгән фактларны мисалга алсак, фәнни тикшеренүчегә бу күренешләрнең сәбәпләренә карата үз хөкемен укытучы фикере белән янәшә куеп карау максатка ярашлы. Моның өчен укытучы белән сөйләшү һәм аны әлеге күренешләрнең сәбәбен аңлатырга тарту, аның фикерен белү бик урынлы. Әлеге мәсьәләләрдә укытучы белән фәнни тикшеренүченең фикерләре туры килү яисә аерылу хакыйкатьне табарга булышыр.

**Мәктәп документларын һәм укучыларның эш нәтиҗәләрен өйрәнү.** Күп кенә педагогик күренешләрне тикшергәндә мәктәпнең эш кәгазьләрен һәм укучыларның эш нәтиҗәләрен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Белем өчен куела торган билгеләрнең укучыларның өлгерешен стимуллаштыру ролен өйрәнгәндә, үткән уку елларындагы сыйныф журналлары һәм өлгереш табельләре белән танышмыйча мөмкин түгел. Мәктәп китапханәсендә укучыларның уку карточкасын өйрәнү аларның нинди китаплар укуын, нәрсәләр белән кызыксынуын һ.б. күзалларга мөмкинлек бирә. Өйгә эш дәфтәрләрен карап чыгу тикшеренүчегә укытучы биргән эшләргә карата укучыларның мөнәсәбәтен һ.б. белергә булыша.

**Педагогик эксперимент.** Бу – укытучылар һәм укучыларның алдан ук билгеләнгән тикшеренү максатларын күздә тотып махсус оештырылган педагогик эшчәнлеге. Бу юнәлештә экспериментларның аныклау (раслау, констатация), иҗади үзгәртү, контроль ясау һ.б. кебек төрләре кулланыла.

*Аныклау (констатация) эксперименты* гадәти тикшеренүләр барышында үткәрелә һәм өйрәнелә торган теге яки бу проблема буенча эшләрнең торышын ачыклауны күздә тота. Мәсәлән, әгәр укучыларның уку эшләренә үзконтроль мәсьәләсе өйрәнелсә, барыннан да элек аныклау эксперименты үткәрелә. Ә аңа исә үз чиратында күп кенә тикшеренү методикаларын, үзконтроль алымнарын ни дәрәҗәдә белүләрен ачыклау максатыннан укучылар белән әңгәмәләр үткәрү һәм анкеталарга җаваплар алу, әлеге сораулар буенча ата-аналар белән әңгәмә

уздыру, дәресләргә әзерлек барышын күзәтү һ.б. керә. Тикшеренү нәтиҗәләренә нигезләнеп укучыларның уку эшләренә үзконтроле турында гомуми йомгак ясала.

Әгәр мәктәп эшендә бу проблема канәгатьләнмәслек хәл ителә дип тапса, фәнни тикшеренүче аны өйрәнүне дәвам итә һәм *иҗади үзгәртү эксперименты* үткәрә, ягъни алдан әзерләнгән план буенча үзконтроль алымнарын укучыларның уку эшләре тәҗрибәсенә кертергә тырыша. Әгәр бу уңай нәтиҗәләр бирсә, алынган мәгълүматлар теоретик яктан анализлана һәм мәктәптә әлеге эш методикасы турында тиешле йомгак ясала.

Бу проблеманы тикшерү барышында алынган мәгълүматларны һәм нәтиҗәләрне гомуммәктәп тәҗрибәсендә сынап карау алдагы этап булып тора. Бу исә *контроль эксперимент* ярдәмендә хәл ителә, ягъни экспериментта расланган методика алдынгы мәктәпләр һәм укытучылар практикасында кулланыла башлый. Әгәр ул методика ясалган нәтиҗәләрне ныгытса, фәнни тикшеренүче аларны гомумиләштерә, алар педагогиканың теоретик һәм методик коралы булып китә.

Педагогик тикшеренүләр методикасында *табигый эксперимент* аерым урын алып тора. Табигый экспериментның асылы шунда: тикшеренүче теге яки бу педагогик күренешләрне анализлаганда педагогик ситуацияләрне шундый итеп төзи, алар укучылар һәм укытучылар эшчәнлегенең күнегелгән барышын бозмыйлар, ягъни гадәти, табигый характерда булалар.

**Алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү һәм гомумиләштерү.** Бу метод педагогикада иң әһәмиятлеләрдән санала. Ул укыту һәм тәрбия эшен уңышлы башкаручы алдынгы мәктәпләр һәм укытучыларның эш тәҗрибәсен өйрәнүгә һәм аны теоретик нигезләүгә таяна. Монда сүз укытучыларның эмпирик юл, ягъни тәҗрибә юлы белән еш кына педагогикада әлегә билгеле булмаган мөһим педагогик ачышлар ясавы турында бара. Гомумиләштерелеп, теоретик яктан нигезләнмәсәләр, бу ачышлар аерым кешеләрнең казанышы гына булып кала. Теоретик яктан нигезләү аларны педагогик фәннәр системасына кертә һәм аның үсешенә булыша.

**Педагогикада фәнни тикшеренүнең социологик алымнары.** Югарыда карап үтелгән фәнни тикшеренү методларының уңай яклары белән беррәттән җитешсезлеге дә бар: алар ярдәмендә галим мәгълүматларны чагыштырмача чикләнгән күләмдә ала, өстәвенә әлеге мәгълүматлар азсанлы мәктәпләргә һәм укучыларга карый. Шул ук вакытта еш кына теге яки бу мәсьәләне киңәйтеп өйрәнү зарурлыгы килеп баса. Мондый очракларда педагоглар *социологик тикшеренү методларын* кулланалар – анкета тарату һәм рейтинг (бәяләү) оештыралар. Мисал өчен, укучыларның буш вакытларын ничек үткәрүләрен ачыкларга кирәк булганда, анкета тарату һәм "Дәрестән тыш вакытларыңда ни белән шөгыльләнәсең?" дигән сорауга җаваплар алу үзен аклый. Шулай итеп, бу мәсьәләне чагыштырмача тизрәк өйрәнергә һәм күбрәк укучылардан сорашып чыгарга мөмкинлек туа. Рейтинг методы ярдәмендә теге яисә бу әхлакый мәсьәләләргә укучыларның мөнәсәбәтен ачыклау һәм аларның әхлакый аң үсеше дәрәҗәсен билгеләү җиңел. Әйтик, укучыларга өч баллы система буенча хезмәт сөючәнлек, коллективизм, намуслылык, принципиальлек һ.б. әхлакый сыйфатларның мөһимлеген бәяләү тәкъдим ителә. Шушы бәяләмәләр нигезендә шәхеснең төрле сыйфатларына аларның мөнәсәбәтен күзалларга була.

Соңгы вакытларда тикшеренүнең математик методлары һәм шул исәптән тикшеренү материалларын статистик яктан эшкәртү алымнары киң кулланыла. Мәктәпләрнең берсендә математика буенча өй эшләренең ничек үтәлүен өйрәнәләр. Нәтиҗәдә өй эшләрен мөстәкыйль эшләүче укучыларның саны дүртенче сыйныфта – 80, алтынчыда – 75, сигезенче сыйныфта 55 процент тәшкил итүе ачыклана. Моның сәбәпләре нәрсәдә, әллә соң әлеге мәктәптә бу фәнне укытуның сыйфаты түбән булудамы, дигән сорау туа. Педагогик тикшеренүләрдә педагогик идеяләр һәм күренешләрне теоретик анализлау методлары әһәмияткә ия. Ул, укыту һәм тәрбиянең мөһим мәсьәләләре буенча тирәнрәк фәнни гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек тудыру өстенә, тикшеренүләрне тәҗрибә методлары ярдәмендә ачыклап булмый торган очракта яңа закончалыклар да таба.

Моны түбәндәге мисалда күрсәтеп үтик. Билгеле булганча, шәхеснең үсеше бербөтен процесс, чөнки шәхеснең барлык сыйфатлары да үзара билгеле бер бәйләнештә үсә. Кайчандыр А.С. Макаренко, кеше өлешләп үсми, дип билгеләп үткән иде. Моннан исә тәрбия барышында шәхеснең һәрьяктан үсешен кайгыртырга кирәк дигән нәтиҗә чыгарыла. Әмма монда бер нәрсә исәпкә алынмый: бербөтен буларак төрлелекне шәхеснең һәрьяктан тигез үсеше белән бутарга ярамый. Теоретик анализ нигезендә түбәндәге нәтиҗәгә киленде: тәрбия эше балаларның һәрьяклап үсешенә юнәлдерелергә тиеш булса да, аны тормышка ашыруның һәр чорында укучыларның үсешендә артта калган якларны ачыкларга, аларны "куалый төшәргә", шәхес буларак үсешне "тигезләү" өчен педагогик көчләрне тупларга кирәк.

Тарихи-педагогик тикшеренүләр барышында, элегрәк эшләгән педагогларның иҗади мирасын яисә педагогик фәннәр үсешенең аерым чорларындагы теге яисә бу проблемаларны хәл итүнең торышын өйрәнгәндә педагогик идеяләрне һәм күренешләрне теоретик анализлау методы киң кулланыла.

Педагогикада кулланыла торган тикшеренүләрнең иң мөһим методлары менә шулар. Әмма бу методларның һәркайсы үзенә генә хас роль башкаруын һәм педагогик күренешләрнең аерым якларын өйрәнүгә булышуын әйтеп үтәргә кирәк. Бу күренешләрне һәрьяклап өйрәнүдә әлеге тикшеренү методлары тулаем кулланыла.

Ләкин тикшеренүдә урнашкан методлар бер генә фәндә дә камил хәлдә булмый. Шуның өстенә, һәрбер фән тикшеренүләрнең яңа методикасын кертү һәм инде урнашкан методларны камилләштерү хисабына гына үсә. Бу тулысы белән педагогикага да карый. Ул тикшеренү методларын даими камилләштерә һәм педагогик күренешләрнең асылына торган саен тирәнрәк үтеп керә. Шулай итеп, педагогик тикшеренүләрдә социологик методиканы куллану укучылар коллективында шәхси симпатия һәм антипатиягә нигезләнгән һәм коллектив эшчәнлегендә аерым әһәмияткә ия булган аерым төркемнәр яшәвенә игътибар итәргә мөмкинлек тудыра.

## 2.3. Вопросы для самоконтроля

1. Каковы главные категории педагогики и связь между ними?

2. Что такое воспитание? Почему одним определением невозможно раскрыть его смысл?

3. Что такое обучение? Что скрывается за понятиями «учение» и «преподавание»?

4. Какая характеристика образования является главной?

## 2.4. Глоссарий по теме 2

**Воспитание** – целенаправленное формирование личности в целях подготовки её к участию в общественной и культурной жизни в соответствии с социокультурными нормативными моделями. По определению академика И.П. Павлова, воспитание – это механизм обеспечения сохранения исторической памяти популяции.

## 2.5. Использованные информационные ресурсы


http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор. РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php

## Тема 3. Шәхес формалашу нигезләре

**Аннотация.** Данная тема раскрывает основы формирования личности. Рассматривается роль наследственности, окружающей среды и воспитания в формировании личности.

**Ключевые слова.** Культура, личность, наследственность, окружающая среда, воспитание.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### 3.1. Кешенең үсешендә нәселдәнлекнең роле

Биологик нәселдәнлек кешене кеше иткән гомуми сыйфатларны да, кешеләрне тышкы һәм эчке яклардан төрле-төрле иткән үзгәлекләрне дә билгели.

И.П. Павлов тәгълиматы буенча, кеше тумыштан ук күп кенә шартсыз рефлекслар төркеменә кергән үзенчәлекләргә һәм инстинктларга ия була. Мәсәлән, азыклану рефлекслары (ризык күргәч селәгәй бүленеп чыгу), саклану (кайнардан кулны тартып алу, көчле яктылыктан күзне йому һ.б.), чамалау (тавыш килгән, якты төшкән якка борылып карау һ.б.). Бу хасиятләр югары үсешкә ирешкән хайваннарга да, кешегә дә хас.

Кешегә хас үзенчәлекләргә ике аякта хәрәкәт итү, сөйләшергә өйрәнү, хезмәткә сәләтлелек керә.

Кешелек тарихыннан мисаллар, шулай ук гаиләдә, кешеләр арасында бала үсешендә табигый шартларның бозылу очраклары кешегә хас үзенчәлек һәм сыйфатларның үсешендә *кешеләр белән аралашу, кешелек җәмгыятендә үсүнең* хәлиткеч һәм төп әһәмияткә ия булуын күрсәтәләр. Балаларны хайваннар алып киткән очраклар, яисә сабый чактан хайваннар арасына эләккән һәм күп

еллардан соң гына табылган балалар билгеле. Алар кешеләргә хас төп сыйфатлардан бөтенләй диярлек мәхрүм: сөйләшә белмиләр, үрмәләп кенә йөриләр, фикерләү сәләте бөтенләй үсмәгән була. Димәк, кешене кеше итүче һәм тумыштан килә торган сәләтләрнең үсеше нәселдәнлеккә генә түгел, барыннан да элек социаль шартларга, кешеләр белән аралашуга, алардан нинди үрнәк алуга бәйле икән.

Ата-аналардагы генның теге яисә бу комбинациясен чагылдыручы генетик программаның нәтиҗәсе буларак, ата-аналардан балаларга тән төзелеше үзенчәлекләре һәм килеш-килбәт, чәч, күз, тән төсләре күчәргә мөмкин. Нерв системасының кайбер үзенчәлекләре дә нәселдән нәселгә тапшырылырга мөмкин. Шуның нигезендә әйләнә-тирә чынбарлык белән үзара тәэсир итешү нәтиҗәсендә билгеле бер югары нерв эшчәнлеге гамәлгә аша.

Организмда төрле аксымнар комбинациясе генетик яктан катгый программалаштырылган, кан группасы, резус-фактор бигеләнгән була. Тумыштан бирелеп, нәселдән нәселгә күчкән барлык шушы физик үзенчәлекләр кешеләрнең эчке һәм тышкы аерымлыкларын билгели.

Ниндидер бер эшчәнлеккә һәвәслекне яисә нинди дә булса өлкәдә осталыкны чагылдыручы сәләтләрнең нәселдән бирелүе педагогика һәм психологиядә шактый бәхәсле мәсьәлә булып тора.

Сәләт дигәндә, шәхеснең билгеле бер эшчәнлек төрләрен уңышлы башкару өчен иң мөһим шартларның берсе булган индивидуаль-психологик үзенчәлекләре күздә тотыла.

Физиология һәм психология мәгълүматлары буенча кешенең сәләтләре әзер килеш тумыштан бирелми, аларның үсеше өчен мөмкинлекләр генә бирелә. Әлеге сәләтләр баш мие, сизү органнары, сөйләм органнарының шәхси структур-функциональ аерымлыкларына бәйләнгән. Моны сәләт үсешенең табигый алшартлары итеп карарга кирәк.

Сәләтләр турында фәнни концепциядә сәләтне эшчәнлекнең чагылышы дип карау өстенлек итә. Бу исә табигый сәләтләрне тормышка ашыруда кешене

үзе булдыра алырлык эшчәнлек төренә тарту һәм аның үзенең хезмәт сөюе — иң мөһим шарт дигән сүз.

Махсус сәләтләргә ия балалар югарырак нәтиҗәләргә ирешә, белемнәрне тизрәк һәм азрак көч куеп үзләштерә. Сәләтләр ачык сизелеп торганда, ал арны тормышка ашыру өчен азмы- күпме шартлар тудырылса (мәсәлән, рәсем ясау өчен кәгазь, карандаш булса), сәләт сабый чактан ачыла-үсә башларга мөмкин. Тәҗрибә шуны да күрсәтә: соңыннан гаҗәеп талантка әверелгән бик зур сәләт тә, әгәр кешегә үз көчләрен эшкә җигеп бу сәләтен ачарга мөмкинлек тудырылмаса, озак вакытлар ачыла алмыйча, йомылып ятарга мөмкин.

Музыкага, әдәби, математик һәм лингвистик шөгыльләргә, мәгълүм дәрәҗәдә техникага хирыслыкны махсус сәләт дип атыйлар.

Педагогика, нинди дә булса махсус эшчәнлекне (мәсәлән, музыка, рәсем сәнгатендә һ.б.) уңышлы башкаруга мөмкинлек бирүче табигый сәләтләрне инкарь итмәстән, бала сәләтенең ачылуы һәм үсеше күбесенчә тормыш шартларына һәм тәрбиягә бәйле, баланың шул сәләтләргә туры килгән эшчәнлек төренә тартылуы да шуның белән билгеләнә, дип раслый. Сәләт үзеннән-үзе генә талантны үстерүдә этәргеч көч булып санала алмый, ул талант үсешенә индивидуаль-табигый алшарт кына булып тора.

Гомуми сәләтнең, аеруча акыл һәм танып белү көчләренең үсеше өчен нигез булган интеллектуаль сәләтнең, нәселдән килүе турындагы мәсьәлә тагын да катлаулырак.

Югары нерв эшчәнлеге типларында булган аерымлыклар фикерләү процессларының барышына мәгълүм үзенчәлек бирә, әмма интеллектуаль эшчәнлекнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләми. Шуның белән бергә, медицина һәм педагогика интеллектуаль сәләтнең үсеше өчен зәгыйфь нәселдәнлекне, мәсәлән, эчкечеләрдән туган балаларның ми ярымшарлары тышчасы күзәнәкләренең сүлпәнлеген, интеллектуаль сәләтнең үсешенә тискәре йогынты ясаучы нәселдән күчкән кайбер авырулар булуын таныйлар.

Шулай да педагогика, сәләт һәм талантларның биологик яктан тигезсез булу ихтималын күздә тотып, укытканда шул аерымлыкларны ачыклауны һәм

аларга җайлашуны түгел, ә һәр балада булган төрле дәрәҗәдәге сәләт һәм талантларны үстерү өчен шартлар тудыруны алга сөрә.

Шәхеснең психик сыйфатлары – яшәү дәверендә барлыкка килгән сыйфатлар, ягъни тормышта организмның тышкы һәм, барыннан да элек, социаль тирәлек белән аралашу процессында формалашкан һәм үсеш алган сыйфатлар, дигән принцип генетика мәгълүматларына нигезләнгән педагогика һәм психологиядә төп принцип булып тора. Кешенең үз-үзен тотышының бернинди социаль яки социаль булмаган программасы тумыштан салынмый, ягъни кешенең социаль яктан үз-үзен тотышы биологик программалаштырылмый. Кешеләр үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм башкаларга мөнәсәбәт турындагы әхлакый кыйммәтләр һәм күзаллаулардан азат булып туалар, һәр кеше өчен социаль үсеш асылда "нульдән" башлана, һәркем өчен ул кабатланмас шартларда (хәтта тышкы шартлар бертөрле үк булса да) бара, һәркемнең әлеге шартларга эчке реакциясе төрлечә, чөнки һәркем үзенчә үсә һәм дөньяга үз шәхси мөнәсәбәтен формалаштыра.

## 3.2. Кешенең үсешендә һәм шәхес формалашуда әйләнә-тирә мохитнең роле

Әйләнә-тирә мохит дигәндә кешегә стихияле рәвештә тәэсир итә торган төрле тышкы күренешләр күздә тотыла. Табигый яисә географик мохитнең, социаль һәм гаилә мохитенең йогынтысы турында сөйләргә мөмкин, һәр мохит кешегә үзенчә тәэсир ясый.

Климатны, табигать шартларын һәм табигый байлыкларны эченә алган географик мохит кешенең яшәү рәвешенә һәм аның хезмәт эшчәнлеге характерына һичшиксез йогынты ясый. Әйтик, тропик зонадагыларның яшәү рәвеше төньякта яшәүчеләрнекеннән нык аерыла, чөнки аларның үсешенә, яшәешенә йогынты ясаучы факторлар төрле-төрле. Гаилә мохитенең йогынты ясау көче бәхәссез.

Педагогикада социаль мохитнең йогынтысы бик мөһим. *Социаль* төшенчәсенә иҗтимагый мөнәсәбәтләр һәм шул мөнәсәбәтләрне җайга салучы институтлар керә. Табигый, социаль мохит җәмгыять үсешенең төрле

этапларында бертөрле булмый, һәм шуңа күрә төрле иҗтимагый-тарихи формацияләр кешеләргә төрлечә йогынты ясый. Мохит йогынтысы кешенең теге яисә бу җәмгыятьтәге кайсы социаль группага керүенә бәйле.

### 3.3. Кешенең үсешендә һәм шәхес буларак формалашуында тәрбиянең роле

Мохит кебек үк, тәрбия дә үсеп килүче кешегә тышкы йогынтының бер формасы булып тора. Тәрбиянең мөһим үзенчәлеге аның максатка юнәлдерелгән һәм планлы булуында. Бу эш тәрбиячеләр җитәкчелегендә тормышка ашырыла. Шулай да тәрбия йогынтысының көче һәм аның нәтиҗәсе күп яктан нәселдәнлек һәм мохит йогынтысына бәйле.

Кешенең үсеше нәселдән килгән физик үзенчәлекләрнең һәм табигый сәләтләрнең чагылышы һәм камилләшүе буларак та, шулай ук әйләнә-тирә чынбарлык йогынтысы нәтиҗәсендә гомер буе формалашкан гаять күп яңа сыйфатлар белән дә характерлана.

Шунысы бәхәссез: тәрбия тән, күз, чәч төсе, гәүдә төзелеше һәм килеш-килбәт кебек физик үзенчәлекләргә йогынты ясый алмый. Әмма шуның белән бергә тәрбия кешенең гомуми физик үсешенә йогынты ясарга мөмкин, чөнки махсус күнегүләр ярдәмендә баланың сәламәтлеген ныгытырга, аны тагын да ныграк һәм чыдамрак итәргә мөмкин, бу исә үз чиратында аның активлыгын, эшкә сәләтен үстерә.

Югары нерв эшчәнлегенең тумыштан килгән тибы үзгәрешсез калмый: тормыш шартлары, аеруча тәрбия һәм үз-үзеңне тәрбияләү нәтиҗәсендә кешенең тормоз процесслары үсәргә һәм ныгырга яки нерв процессларының көче һәм хәрәкәтчәнлеге артырга мөмкин. Бу исә тумыштан килгән югары нерв эшчәнлегенә күпмедер дәрәҗәдә тәэсир итәргә, аның кискен формадагы чагылышларын йомшартырга мөмкин. Шуңа күрә бу очракта да, тәрбия кешенең нәселдән килгән эчке үзенчәлекләре үсешенә тәэсир ясый ала, дип әйтергә була.

Табигый сәләтлелек билгеләре бары тик тәрбия йогынтысында һәм кешене теге яки бу эшчәнлеккә тарту нәтиҗәсендә генә сәләткә әверелергә мөмкин.

Тәрбия сәләтлелек билгеләренең һәм сәләтнең ачылуын һәм камилләшүен билгели: тәрбия йогынтысында беленер-беленмәс сәләт тә үстерелергә мөмкин, шул ук вакытта дөрес бирелмәгән тәрбия хәтта көчле сәләт үсешен дә тоткарларга һәм туктатырга, яисә зәгыйфь сәләтлелек билгеләрен бөтенләй томаларга мөмкин.

Нинди дә булса эшчәнлеккә һәвәслек яисә билгеле бер нәрсә белән кызыксыну еш кына әлеге сәләтлелекнең чагылышы ул.

Шуңа күрә укучының шундый һәвәслекләрен ачыклау һәм аны үзен кызыксындырган өлкәдә гамәли эшчәнлеккә тарту тәрбиянең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

Шунысы да мәгълүм: сәләтлелек билгеләрен үстерү, аларны чын сәләткә әверелдерү һәм хәтта талантны үстерү өчен дә булдыклылык, хезмәт сөючәнлек зарур. Ә хезмәт сөючәнлек, озаклап һәм мавыгып эшли алу – болар иң элек тәрбия нәтиҗәсендә ирешелгән сыйфатлар.

Кешене шәхес буларак формалаштыруда тәрбиянең төп ролен исбатлау өчен тумыштан сукыр һәм чукрак балаларны тәрбияләү, өйрәтү, тормышка тарту буенча тупланган тәҗрибә бик әһәмиятле, һәм ул гаять зур фәнни кызыксыну уята. Мондый балаларның тормыш белән барлык элемтәләре һәм кирәкле белем, осталык һәм күнекмәләр алуы тәрбияче җитәкчелегендә башкарыла. Аларны тәрбияләү методикасының нигезе – бергәләп һәм бүленешле эшчәнлек. Бу процесста тәрбияче, балада мөстәкыйль эшләү омтылышлары уянуын хуплау максатында, үз җитәкчелеген киметә бара.

Бу эшнең әһәмияте махсус педагогика белән генә чикләнми, чөнки ул тәрбияче җитәкчелегендә кеше психикасының уянуын һәм формалашу процессын күрергә һәм танып белү теориясен алга үстерергә булыша.

Педагогика, балаларны укытудагы билгеле бер аерымлыкларны таныган хәлдә, баланың киләчәк үсешенә йөз тота һәм фикерләүне үстерә торган укыту ягында тора. Монда укытучы баланың танып белү эшчәнлеген һәм активлыгын тиешенчә оештыру юлы белән аның үсешенә ярдәм итәргә тырыша.

Психиканың һәм әхлакый күзаллауларның үсеше – яшәү чорында формалаша торган өлкә, анда төп роль тәрбиягә бирелә.

Уңай социаль тирәлек һәм яшәү рәвешенең уңай йогынтысы шартларында мәктәп яшьләрне тәрбияләүдә мөһим роль уйный, бу исә педагоглар һәм укучылар коллективының максатка юнәлдерелгән эшчәнлеге белән билгеләнә.

### 3.4. Вопросы для самоконтроля

1. В чем смысл духовного развития человека?
2. Какими общими условиями и факторами определяется развитие?
3. Какова роль наследственности в развитии?
4. Как влияет на развитие человека среда?
5. Как влияет на развитие человека воспитание?
6. Как связано развитие с деятельностью и активностью человека?
7. Как связано развитие с возрастом?

### 3.5. Задания для практики

Подготовьте «карту ума» по профессионально значимым личностным качествам педагога.

Ознакомиться с текстом документа «Тема 3», добавить вопросы для самоконтроля.

### 3.6.Глоссарий по теме 3

**Профе́ссиогра́мма** – система признаков, описывающих ту или иную профессию, а также включающая в себя перечень норм и требований, предъявляемых этой профессией или специальностью к работнику. В частности, профессиограмма может включать в себя перечень психологических характеристик, которым должны соответствовать представители конкретных профессиональных групп. Помимо вышеперечисленного, профессиограммы зачастую используют при разработке антикризисной кадровой политики.

**Профессионализм** – совокупность личностных характеристик человека, необходимых для успешного выполнения педагогической деятельности.

**Педагогическая направленность** – система доминирующих мотивов: интересов, потребностей, склонностей, побуждающих к профессиональной деятельности.

### 3.7. Использованные информационные ресурсы

http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор. РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php

## Тема 4. Укытучы эшчәнлеген иҗади оештыру

**Аннотация.** Данная тема раскрывает общение как основу педагогической деятельности. Рассматриваются стили педагогического общения.

**Ключевые слова.** Общение, авторитарный стиль, демократический стиль, попустительский стиль.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### 4.1. Укытучы эшчәнлеген иҗади оештыру

Мәктәп үсешенең хәзерге шартлары һәм мәгариф эшен оештыруның яңа формалары укытучы хезмәте эчтәлеген, аның һөнәри әзерлеген һәм квалификация дәрәҗәсен, укытучыларны аттестацияләү ысулларын билгеләү, мәктәп эшчәнлегенә фәнни тикшеренү кертү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү бурычын куя.

Дәүләт яшь буынга белем һәм тәрбия бирүне иң әһәмиятле эш дип саный һәм үз идеяләрен мәктәп аша гамәлгә ашыру өчен укытучыга киң иҗат иреге тудыра.

Укучыларны төрле формада укыту, шул исәптән шәхси мәктәпләр ачу хокукы бирелә. Әмма белем алу формасын, методларын, эчтәлеген сайлау иреге, көйләп булмый торган мөнәсәбәтләр барлыкка килү нәтиҗәсендә мәгариф системасында халыкара дәрәҗәдә һәм дәүләт (федераль) дәрәҗәсендә конверсияләнмәүче белгечләр әзерләнә башлады. Ә бу мәктәп һ.б. уку йортлары тәмамлаган кешеләрне эшкә алганда аларның белем дәрәҗәләрен тикшерүгә өстәмә чыгымнар тотуны сорый, дәүләт мәгариф системасын тергезү һәм үстерүдә кыенлыклар барлыкка китерә.

Яңа икътисади шартларда укытучы хезмәтен стандартлаштыру процессы яшәп килүче мәгариф системасын камилләштерү, укытучының өр-яңа форма, чара, методлар куллануы мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән. Аның ярдәмендә белемнең абруен күтәрергә, укучыларның мәктәптән читләшүен булдырмаска, һәр дәрәҗәдә белем бирүне гамәлгә ашыруда бердәм сәясәт алып барырга мөмкин.

Укытучы хезмәтен стандартлаштыру илдә мәгариф системасын камилләштерүгә бәйле күптөрле мәсьәләләрне хәл итәргә, шулай ук аттестация, тарификация үткәрергә, квалификация характеристикасы төзергә, хезмәт өчен яңача түләү ысуллары кертелү шартларында сәләте һәм белеме нигезендә укытучының квалификация дәрәҗәсен билгеләргә ярдәм итә.

Бу очракта стандартны укытучы хезмәтенә норма, кагыйдә, таләпләр комплексын билгеләүче норматив документ дип аңларга кирәк. Ул мондый таләпләргә җавап бирергә тиеш: объективлык (тикшерүче ихтыярына бәйсез); хезмәтне бәяләүче һәр юнәлешнең әһәмияте; фәнни (стандартка кертелә торган төп юнәлешләрнең (критерийларның) җитәрлек һәм төгәл фәнни нигезләнгәнлеге); гамәли юнәлешле (мәктәп эшчәнлегенең тормыш белән бәйләнеше); юнәлешләрне гамәли эшчәнлектә файдалану мөмкин булуы: мәгариф өлкәсендә кабул ителгән башка стандартлар белән бәйләнеш; укытучы хезмәте стандарты юнәлешләренең укыту максатлары белән элемтәсе; диагнозлылык (тәкъдим ителә торган юнәлешләр нигезендә укытучы хезмәте квалификациясенең теге яки бу дәрәҗәсенә дөрес диагноз кую).

Нәтиҗәле эшләүче укытучы – үсеп килүче мәгариф системасы педагогы. Ул үзе укыта торган фән, философия, психология, физиология, педагогика, социология өлкәсендә тулы структуралаштырылган белемле булырга, укучының аң-фикер эшчәнлеге формалашу һәм үсү процессын, баланың сәләтен, тормышта төрле хәлләргә очраганда үз-үзен тоту төрләрен (вариантларын) белергә, педагогик технологияләргә ия булырга тиеш.

Укытучы хезмәтен стандартлаштыру эше мондый эшчәнлекне анализлауны истә тотарга тиеш:

— укытучының белем һәм күнекмәләре; аның һөнәри әзерлеге дәрәҗәсе;

— квалификациясен бәяләү критерийлары;

— педагогик хезмәт нәтиҗәләрен бәяләү нормалары;

— педагогик осталыкны арттыру, квалификация дәрәҗәсен үстерү алымнары;

— укытучыны аттестацияләү, аның хезмәтенә түләү дәрәҗәсе;

— белем бирү учреждениесенең эш шартлары, хезмәт характеры, үсеш перспективасы һ.б.

Шундый анализ ясалганнан соң, укытучы хезмәтен төрле яктан тиешле дәрәҗәдә бәяләүче төгәл юнәлешләр билгеләнергә, алар стандарт булырга да мөмкин. Укытучының төп эшчәнлеге характеристикасын юнәлешләр сыйфатында да файдаланырга була. Аларны үтәү дәрәҗәсе укытучы квалификациясенең төп күрсәткечләре буларак кабул ителә һәм аның хезмәтен дөрес бәяләү нормасы булып тора.

Билгеле булганча, укытучы эшчәнлеге укыту процессын проектлау, конструкцияләү һәм гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән. Шуннан чыгып, педагогикада *проектлау, конструктив, коммуникатив эшчәнлек* төрләре билгеләнгән.

*Проектлау эшчәнлек төре* – уку процессын төгәл педагогик шартларда проектлау, *конструктив эшчәнлек* шәхси методика эшкәртү белән бәйле. *Коммуникатив эшчәнлек* – уку материалын белем алу процессында үзләштерерлек итеп аңлату. Бу эшчәнлек төрләренең барысы да нинди генә формада гамәлгә ашырылса да, укыту процессының нәтиҗәсе һәм сыйфаты белем бирү максатын дөрес билгеләү күнекмәсенә нигезләнгән.

Укытучының проектлау эшчәнлеге укытуның гомуми максаты һәм бурычларына, уку материалы эчтәлегенең катлаулылыгына һәм укучыларның аны кабул итәргә әзерлек дәрәҗәсенә карап төрле педагогик технологияләрне куллана белүгә бәйле.

Конструктив эшчәнлек, укучының иҗади эшчәнлеген, бала шәхесен үстерүгә һәм дәреснең дидактик максатларын камилләштерүгә юнәлтелгән

укыту максатларыннан чыгып, укытучыга балаларны нәтиҗәле укыту алымнарын дөрес билгеләү (алдан күрү) мөмкинлеге тудыра.

Коммуникатив эшчәнлек материалның әйбәтрәк үзләштерелүенә ирешү максатында балаларга белемне ничек бирергә кирәклеген дөрес билгеләү алымнарына бәйле.

Эшчәнлек төрләрен шулай аңлатудан чыгып, аттестация үткәрү һәм билгеле бер квалификация дәрәҗәсе бирү өчен, укытучыга аның хезмәт стандарты эшкәртмәсе юнәлешләре тәкъдим ителергә мөмкин. Алар эшчәнлекнең төп төрләренә карап бәяләүгә юнәлтелгән:

— проектлау эшчәнлеге буенча: укытучының гамәли эшчәнлегендә кулланыла торган укыту технологиясенең саны һәм сыйфаты (мөмкин булган педагогик хәлләргә бәйле рәвештә бер үк педагогик мәсьәләне берничә төрле ысул кулланып хәл итү күнекмәсенә ия булу);

— конструктив эшчәнлек буенча: тәкъдим ителгән биремне үзләре теләп иҗади үтәү юлын сайлаган һәм шул биремне иң кызыклы алым кулланып чишкән укучылар (алар контроль тикшерү өчен сайлап алына) саны буенча укытучы хезмәте эшчәнлеге билгеләнә;

— коммуникатив эшчәнлек буенча: белемне укытучы планлаштырган үзләштерү дәрәҗәсеннән һәм уку материалының катлаулылыгыннан чыгып, уку материалын үзләштерү тизлеген истә тотып, укучыларга укыту процессында мәгълүмат бирү ысуллары.

Шулай итеп, укытучының эш процессында файдаланыла торган укыту технологияләре саны төрле ысуллар белән (телдән, язмача) тикшерелергә мөмкин. Тәкъдим ителгән биремне катлаулы ысул кулланып үтәргә теләгән укучылар санын билгеләү дә кыенлык тудырмый. Бу методлар дәреснең дидактик максаты нигезендә укучылар алдына куелган бурычларны гамәлгә ашырырлык иҗади якын килүгә нигезләнә.

Моны ике төрле юл белән гамәлгә ашырырга мөмкин: барлык укучыларга да бертөрле бирем бирелә һәм аны мөмкин булган өч төрле ысул белән үтәргә тәкъдим ителә. Мәсәлән, сорауга җавап бирергә; мәсьәләне аңлатмыйча гына

алгоритм буенча чишәргә; мәсьәләне аңлатып чишәргә. Биремне үтәгәндә сорауга яңача җавап бирү турында уйларга һәм үз фикереңне тәкъдим итәргә.

Башка төрле юл да кулланырга мөмкин: әйтик, төрле-төрле өч бирем тәкъдим ителә, ди. Аларның һәрберсе билгеле бер катлаулылыкны күздә тота, һәм иң катлаулы биремнәрне сайлаган укучыларның исәбе алына.

Биремнәрне иҗади үтәргә омтылучы укучыларның санын белгәч һәм аны бу методика нигезендә бер ай, ике ай, ярты ел элек уздырылган контроль тикшерү нәтиҗәләре белән чагыштыргач, укытучы иҗади эшли, үзе укыта торган фәнгә кызыксыну тәрбияләргә омтыла һәм укучыларның аң-фикер эшчәнлеген тергезү һәм үстерүгә юнәлтелгән укыту максатларын уңышлы үти, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин була.

Уку материалының үзләштерелү тизлеген исәпкә алып, белем алу процессында укучыларга мәгълүмат тәкъдим итү ысуллары тиз билгеләнә һәм аларны ачыклау әллә ни кыен булмый.

Алар укучыларның уку материалын үзләштерү дәрәҗәсенең укытучы планлаштырган күрсәткечләре белән әлеге материалның катлаулылык дәрәҗәсен чагыштыруга нигезләнә.

Балаларның белемнәрне үзләштерү характеристикасын һәм уку материалының катлаулылык дәрәҗәсен билгеләү уку материалының ни дәрәҗәдә тизрәк үзләштерелүен билгеләргә ярдәм итә. Уку процессында ул күрсәткечләрдән файдалана белү, укытучы дәрестә тәкъдим итә торган мәгълүматның күплеген, укучыларның үзләштерү мөмкинлегенә туры килүен билгеләү укытучының квалификация дәрәҗәсен бәяләгәндә әһәмиятле санала.

Уку материалын үзләштерү дәрәҗәсе аң-фикер эшчәнлеген оештыру этапларыннан чыгып билгеләнергә мөмкин. Ул этаплар:

— эчтәлеге белән танышу максатыннан уку материалын аңлау;

— әлеге материалны фикер аша үткәрү (аның элегрәк алган белемнәр белән бәйләнеше);

— уку материалын ныгыту (белемнәрне төрле очракта куллану);

— ижат итү (алдан анализлауны таләп итә торган яңа хәлләрдә белемнәрне файдалану).

Уку материалының катлаулылык характеристикасы:

— *аңлатмалы* – уку материалын киңәйтелгән характеристикадан һәм анализлардан башка гына бәян итү;

— *сыйфатлылык* – фәнни нигезләүне һәм киңәйтелгән характеристика бирү;

— *санлы* – үлчәү техникасын һәм математик исбатлауларны файдалану;

— *аксиоматик* – төпле исбатлауларга нигезләнгән материал, алга таба ул аксиома сыйфатында кулланыла.

Уку материалының катлаулылык дәрәҗәсе һәм белемнәрне үзләштерүнең планлаштырган дәрәҗәсе арасындагы чагыштырма буенча укытучының уку материалын оптималь аңлату тизлеген билгеләргә була. Коммуникатив эшчәнлек структурасы укытучының дәрестәге эшчәнлек структурасы буларак тәкъдим ителергә мөмкин. Аңа оештыру, тәрбия эшчәнлеге, дидактик, методик эшчәнлек, укучылар эшчәнлеген бәяләү, педагогика техникасы керә.

Санап үткән эшчәнлек төрләре түбәндәге төп күрсәткечләр буенча анализланырга мөмкин.

*Укытучының оештыру эшчәнлеге:*

— дәреснең дидактик максатына ирешүне оештыру;

— укытучының дәрескә куела торган психологик-гигиеник таләпләрне үтәве;

— укыту процессында укучылар белән кире элемтәне оештыру;

— укучыларның дәрестә танып белү эшчәнлеген активлаштыруның төп алымнарын куллану;

— уку вакытын дөрес файдалану һәм бүлү;

— дәрестә язу эшен оештыру, уку әдәбиятын һәм методик әдәбиятны файдалану.

*Тәрбия эшчәнлеге:*

— хезмәткә ихтыяж һәм эштә яхшы нәтиҗәләргә ирешү ихтыяҗы булдыру;

— үзара ярдәмләшү, күмәк эшчәнлектә катнашу күнекмәсе тәрбияләү;

— дәрестә акыл тәрбиясе, эстетик һ.б. тәрбия эше төрләре принципларын гамәлгә ашыру;

— һөнәри юнәлеш бирү, фән белән кызыксынуга омтылыш формалаштыру;

— шәхестә укытуның гомуми максатларына, теге яки бу төбәкнең тәрбияви бурычларына туры килә торган уңай социаль әһәмиятле сыйфатлар тәрбияләү;

— оештыру, методик эшләрнең һәм тәрбияви тәэсир итүнең бердәмлегенә ирешү;

— укыту эшчәнлеге белән идарә итүнең оптималь ысулын билгеләү, ул билгеле бер педагогик ситуациягә туры килергә тиеш;

— тәрбия эшендә укытучының шәхси сыйфатларын файдалану.

*Дидактик һәм методик эшчәнлек:*

— дидактиканың төп принципларын гамәлгә ашыру;

— укытуның гомуми максатлары һәм сыйныфның педагогик мөмкинлекләре нигезендә дәреснең дидактик максатларын яки уку процессын оештыруның башка формаларын билгеләү.

Гомуммәктәп бурычларын тормышка ашыру, мәктәптәге барлык укыту-тәрбия процессын камилләштерү кебек үк, укытучыларның иҗади табышлары нинди тизлектә башкаларның да казанышы була алуына бәйле. Алдынгы укытучының педагогика фәне билгеләгән принципларны, методларны уңышлы куллануга нигезләнгән һәм югары нәтиҗә бирә торган тәҗрибәсе педагогик осталыкка ирешеп өлгермәгән укытучылар өчен яхшы үрнәк булып тора. Иң яхшы тәҗрибәне актив һәм максатчан үзләштерү, эшнең нәтиҗәле методларын иҗади эзләү укытучыларга белемнәрен тирәнәйтергә, осталыкларын камилләштерергә ярдәм итә.

Мәктәп җитәкчеләре, мәгариф идарәләре хезмәткәрләре, педагогик коллективларның эшләренә анализ ясаганда, аларны алдагы еллар нәтиҗәләре белән, башка мәктәпләр белән янәшә куеп карыйлар, аерым укытучыларның эш нәтиҗәләре белән чагыштыралар.

Укытучы практикасындагы иҗат, эзләнү, яңалык, оригинальлек элементлары билгеләнә. Моның әһәмияте күп кенә тикшеренүчеләр тарафыннан ассызыклана.

Уңай нәтиҗәләргә ирешкән укытучыларның эшен элементлап анализлау бик мөһим.

Педагогик нәтиҗәлелек күзлегеннән чыгып караганда, укытучы эшенең кайсы элементлары күбрәк кызыксындыра соң? Укытучыда укучыларны белемнәр белән коралландыру, ал арда күзәтүчәнлек, фикер йөртә белү, хәтерне үстерү, дөньяга караш формалаштыруның конкрет бурычлары булу, укытучының бу бурычларны аңлавы, аларны укучыларга җиткерү һәм практикада куллану дәрәҗәсе. Алдынгы тәҗрибәне өйрәнгәндә, педагогик процессның состав өлешләре буларак укыту материалы, укытучы эшчәнлеге, укыту процессын матди яктан баету, укытуның нәтиҗәләре һ.б. карала, башка педагогларның тәҗрибәне файдалану мөмкинлеге билгеләнә.

### 4.2. Вопросы для самоконтроля

1. В чем особенности педагогической деятельности?

2. Какова структура педагогической деятельности.

3. Назовите важнейшие ценностные характеристики педагогической деятельности.

### 4.3. Задания для практики

Ознакомиться с текстом документа «Тема 4», добавить вопросы для самоконтроля.

## 4.4. Глоссарий по теме 4

**Педагогическая деятельность** – это деятельность, которая обеспечивает отношения, возникающие между людьми при передаче духовно-практического опыта от поколения к поколению.

## 4.5. Использованные информационные ресурсы

http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор. РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php

## Тема 5. ПЕДАГОГИК ХЕЗМӘТТӘШЛЕКНЕҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

**Аннотация.** Данная тема раскрывает пути профессионально-личностное становление и развитие педагога. Рассматриваются слагаемые профессионально-личностного самосовершенствования учителя.

**Ключевые слова.** Самосовершенствование, самовоспитание, самореализация.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### 5.1. Педагогик хезмәттәшлекнең төп юнәлешләре

Хәзерге вакытта белем бирү аралашу процессы буларак аңлатыла. Шуңа күрә укытучыдан укучылар эшчәнлегенең барлык үзенчәлекләрен белү таләп ителә. Бу исә укыту темпын һәм шәхеснең акыл эшчәнлеген уңай якка үзгәртүгә ярдәм итә. Әмма шуны да әйтеп үтәргә кирәк: һәр баланың да үзенчә фикерләвен, үзенчә истә калдыруын, хиссиятен, ихтыяр көчен, һәвәслеген һәм ихтыяҗларын педагогның искә алмавы, шулай ук әлеге сыйфатларны үстерү өчен тиешле шартлар булдыру юнәлешендә эшләмәве шәхес формалаштыруда төп киртә булып тора.

Белем бирү эшен үзара хезмәттәшлек шартларында оештыру – укучыны үзгәртү-тәрбияләүнең төп ысулы. Укытучы һәм балаларның үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә шәхеснең ихтыяҗы һәм сәләте тулысынча ачыла. Бу очракта педагог та, укучы да бер-берсенең ярдәмчесе, киңәшчесе булырга тиеш.

Ә хәзер мондый үзара хезмәттәшлекнең асылы һәм принциплары турында сүз алып барыйк. Моның өчен бер дәрес барышын һәм укытучының укучылары белән үзара эшчәнлеген күзәтик.

...Математика дәресе бара. Укытучы укучыны такта янына чакыра һәм аңа үзе әйткән мисалны тактага, ә башкаларга дәфтәрләренә язарга куша. Эшне тәмамлагач, бала иптәшләренә карый, алар дан ярдәм көтә. Иптәшләре ул чишкән мисаллардагы хаталарны әйтәләр. Мисалларны ничек чишү турында фикер алышу бара. Укучы җавапларны сөртә, иптәшләре тәкъдим иткәннәрне яңадан яза. Укытучының мондый хәлгә ачуы чыга:

– Дәрескә тагын әзерләнмәгәнсең. Шушы гади генә мисалларны да чишә белмисең. "2" ле куям. Көндәлегеңне бир. Әти-әниең ничек тырышып укуыңны күрсеннәр. Әйт үзләренә, иртәгә үк мәктәпкә килсеннәр. Алар белән сөйләшәсе бар, - ди.

Хәзер икенче укытучы дәресендә булыйк.

"Балалар, без бүген үткән дәрес материалын кабатлыйбыз. Ул шактый авыр. Аны сезнең ничек үзләштерүегезне беләсем килә. Башта мондый мисалны чишеп карыйк. Аны тактада Рәшит чишәр. (Укытучы малайга башта фикер тупларга, мисалны мөстәкыйль чишәргә куша. Аннары аңа иптәшләренең ярдәм итәчәген әйтә.) Рәшиткә беркем дә бер сүз әйтмәсен. Шулай сүз куешыйк. Ә башкалар мисалларны дәфтәрләрендә чишсеннәр", - ди ул.

Балалар мисалларны чишәләр. Рәшиткә җавапларны әйтмәкче булалар. Укытучы аларны әкрен генә туктата. Тактада мисаллар чишелеп беткәч, бергәләп, ал арның дөреслеге тикшерелә. Укучылар бер мисалның җавабы дөрес түгеллеген әйтәләр. Дөрес җавап табыла. "Рәшит, мисалны ни өчен дөрес чишмәвеңне аңладыңмы инде, кагыйдәне искә төшердеңме?" - ди укытучы. Аннары: "Балалар, тагын кайсыгыз мисалны Рәшит кебек чиште?" - дип, башкаларга мөрәҗәгать итә. "Рәшит, син урыныңа утыр. Билгене соңыннан куярмын. Хәзер барыгыз да дәфтәрләрдә мисалларны чишегез", - ди.

Мисаллардан күренгәнчә, ике дәрестә дә тулы уңышка ирешелми. (Такта янына чакырылган балалар мисалны дәрес чишми.) Әмма шуны билгеләп үтәргә кирәк: беренче очракта укытучы белән укучы арасында киеренке мөнәсәбәт барлыкка килә. Икенчесендә исә укучының авыр эшне эшләргә

омтылышы сүндерелми, чөнки ул укытучының аңа булышырга әзер торуын, ялкауланмаска, кыенлыкларны җиңәргә өндәвен сизә. Укытучы "2"ле кую, көндәлеккә язу белән дә янамый. Бала уку, белем алуның җиңел түгеллеген, моның өчен тырышырга кирәклеген аңлый.

Моннан шуңа төшенергә була: икенче очракта бөтенләй башка психологик халәт булдырыла. Төп аерма шунда: дәрестә үзара хезмәттәшлек хакимлек итә. Анда укытучы – балаларның дусты, киңәшчесе. Мондый дәрестә укучының ни дәрәҗәдә белемле булуы, аның кайсы теманы аңлап җиткермәве, аңа нинди ярдәм кирәклеге тулысынча ачыклана. Үзара хезмәттәшлек иткәндә кешенең бөтен сыйфатлары күренә. Моңа ирешелмәгәндә бернинди үсеш булмый. Әмма, үзен белемлерәк, яхшырак итеп күрсәтү өчен, укучы тискәре сыйфатларын яшерергә омтыла. Мондый вакытта бала тагын да күбрәк хаталар ясый.

Хезмәттәшлек шәхестә билгеле бер сыйфатлар тәрбияләргә дә ярдәм итә. Характерларның кабул ителгән классификациясенә мөрәҗәгать итеп, моны карап үтик.

Беренче төргә эшне күп уйлап тормыйча эшләүче, инициативалы, шат күңелле, хисләргә тиз бирелүчеләр керә. Әлеге сыйфатларга ия булучыларны *гипертимик* диләр. Мондый балалар башкалар белән тиз аралашалар. Алар, гадәттә, яңа эш белән шөгыльләнергә яраталар, бик күп эш планлаштыралар, ләкин сүзләрендә тормыйлар, тиз кызып китүчән булалар, бер эшне башкарганда икенчесе белән мавыгалар, эшне җиренә җиткереп үтәү турында әллә ни уйламыйлар.

Укытучының мондый укучы белән хезмәттәшлеге чын күңелдән сөйләшү, аңлашу юнәлешендә бара. Нинди дә булса эшне эшләргә бик тиз ризалашуына карамастан, аны һәрчак җентекләп күзәтеп, тикшереп торырга, эшне үтәү вакытын билгеләргә, эшчәнлекнең төгәл максатын, үтәү режимын, әйтергә һәм, максатка ирешелгәндә, эшне тырышып башкаруын башкалар алдында билгеләп үтәргә кирәк.

Кеше характерының икенче төре беренчесенә капма-каршы. Андый холыклы кеше үз эченә бикләнгән, эш эшләргә атлыгып тормый, кыенлыклар

алдында каушап кала. Укытучы белән бик теләп аралашмый. Әмма җитди, итагатьле, ышанычлы, төп мәсьәләне сизү-күрү сәләтенә ия булуы педагогка аның белән тирәнтен аралашырга мөмкинлек бирә. Характерның мондый төрен *дистимик* диләр. Белем алудан тәм тапсын өчен, андый укучыны еш мактарга кирәк. Шул вакытта ул яхшырак укый, укытучы таләпләрен җиренә җиткереп үти башлый.

Характерның өченче төренә ия булганнарның кәефе бик тиз үзгәреп тора. Моны *циклы* характер дип йөртәләр. Андый кеше берара үзен таулар җимерердәй көчле итеп сизә. Бераздан сүрелә, кәефе кырыла. Үзен көчле итеп сизгәндә, ул эшне тиз башкара. Ә энергиясе кимегәч, ялкаулана, эшкә битараф карый. Мондый сыйфатларга ия булган укучы башкаларга күңелсезләнергә ирек бирми, ул шат күңелле, төрле маҗаралар турында сөйләп, иптәшләрен көлдерә. Шуңа күрә педагог аны рухландырып тора: "Синнән башка безгә күңелсез булыр иде", - ди.

Дүртенче төргә бик тиз *"кабынып китүчеләр"* керә. Мондыйлар үз-үзләре белән идарә итә алмыйлар, башкалар белән аралашырга яратмыйлар, аз сөйләшүчән, ачулы булалар, юкка-барга да үпкәлиләр. Вак-төяк мәсьәләләргә дә нык игътибар итәләр, башкаларның җитешсезлегенә түзеп тора алмыйлар, һәрвакыт ризасызлык белдерәләр. Алар, кызып китеп, кирәкмәгән сүзләр әйтергә мөмкин. Кисәтүләрне ошатмыйлар. "Ни өчен гел миңа гына кисәтү ясыйсыз, башкалар да минем шикелле үк бит. Мин дә башкалардан ким түгел", - дип, укытучыга үпкәлиләр.

Аңлашылганча, мондый каршылык укытучының укучы холкын аңлап бетермәвеннән килә. Бала нечкә күңелле, шуңа күрә аңа кисәтүләр дә, тавышны күтәрмичә генә, изге ният белән ясалырга тиеш. "Син, бәлки, бу биремне башкачарак үтәрсең? Үзең ничек уйлыйсың? Минемчә, синдә бу биремне үтәрлек көч тә, сәләт тә бар" кебек киңәшләр мондый укучы өчен үтемле һәм файдалырак була.

Бишенче төрне *"тоткарланучы"* холык диләр. Мондый холыкка ия булган укучы кире, тыңлаусыз, кешеләрнең тискәре мөнәсәбәтенә бик сизгер. Ул

башкаларның үзенә карата әйтелгән сүзләрен озак вакыт исеннән чыгармый, үзен үпкәләткән кешеләр турында күп уйлана, ягъни фикерен шу ларда "тоткарлый", үзен кемнәндер курыккан кебек хис итә. Ясалган кисәтүләрне, эшенә, тәртибенә бирелгән бәяне авыр кичерә. Андый укучы еш кына: "Нәрсә генә эшләсәм дә миңа үчләшәсез, мине генә ачуланасыз. Әйтерсең барысына да мин гаепле", - ди.

Мондый холыклы балага башкарылачак эшнең әһәмиятен аңлату, аны һичшиксез үтәячәгенә инандыру зарури. Менә шул вакытта ул үзенең көченә һәм уңышка ирешәчәгенә ышаначак. Нәрсәнең аңа уңай тәэсир итүен, нинди эшне күңеле теләп башкаруын белү дә әһәмиятле. Шул чакта гына ул укытучыга теләктәшлек белдерә башлый.

*Педантлык* кеше холкының алтынчы төрен тәшкил итә. Сүзлектә бу сүзгә "бик вакчыл кеше" дигән аңлатма бирелгән. Холкы ягыннан бу төргә кергән бала эшне бик әкрен, төгәл башкара. Тышкы кыяфәте әллә ни ышаныч тудырмый, шулай да ул ышанычлы киңәшче, фикердәш, вакыйгаларга дөрес бәя бирә, кыюрак, хәрәкәтчәнрәк балалар белән әллә ни аралашмый. Мәсьәләне бик тиз генә дөрес хәл итәргә кыенсына. Шуңа күрә озакка сузмыйча гына эш эшләүне яисә фикерләүне таләп итә торган ярышларда оттырырга мөмкин. Менә шушы сәбәпләр укытучыга аның белән хезмәттәшлек итүне кыенлаштыра.

Тагын шуны да билгеләп үтәргә кирәк: мондый холыклы бала теләсә кем белән аралашмый, аның танышлары, дуслары аз була. Шуңа да карамастан ул тиз ышанучан, йомшак күңелле, эшкә җаваплы карый, күндәм, тормыш турында сөйләшергә ярата. Уңышсызлыкларга тирәнтен һәм озак борчыла. Укытучы белән мөнәсәбәте начарлануны да авыр кичерә. Ул бик хисле, әгәр дә укытучы кичерешләрен, халәтен аңласа, аның белән хезмәттәшлек итү уңышлы булачак.

Кыюсыз, куркак, үз-үзенә ышанмаучы кешеләрне *хәвефле* характерлар төркеменә кертәләр. Шул сыйфатларга ия булучылар шикле компанияләрне яратмыйлар, бик тиз куркалар, әмма иптәшләре, укытучылар белән дустанә

мөнәсәбәттә, күндәм булалар, педагогларга ярарга тырышалар. Ләкин җаваплылыктан куркалар, ал ардан теге яки бу эш оештыру таләп ителсә, каушап калалар. Гадәттә, андый бала барлык укучы эшләргә тиешле эшне үзе генә башкарырга омтыла.

*Демонстратив* характерлылар башкалар белән бик тиз уртак тел табалар, һәрвакыт укытучы тирәсендә чуалалар, аның белән киңәшләшәләр. Җавапларын белсәләр дә, сораулар бирәләр. Болар укытучының игътибарын үзләренә юнәлтү өчен эшләнә. Алар, мактау сүзләре ишетү өчен, таләп ителмәгән эшләрне дә эшләргә мөмкин (мәсәлән, кайберәүләр сочинениегә иллюстрацияләр ясыйлар). Бу балалар шигырь сөйләргә яраталар. Кызгандыру, яраттыру сәләтенә дә ия булалар.

Мондый холыклы укучы белән хезмәттәшлек иткәндә аның икейөзле булып үсмәве, аны "мин-минлек" чиреннән коткару өчен тырышу сорала. Андый бала дәрескә әзерләнеп килмәсә дә укытучыны ышандырырлык дәлилләр уйлап таба.

Әмма укытучыга түземле булу, баладагы тискәре сыйфатларны бетерү өчен көрәшү, аның үтемле алымнарын табу зарур.

Характерның соңгы төренә тәэсирлелек *(патетик),* артистлык сәләтенә ия булу, кече күңеллелек кебек сыйфатлар хас. Мондый холыкка ия булучылар кайгы яки шатлыкны тирән кичерәләр, нечкә күңелләләр, теге яки бу хәлгә борчылып, кинәт кенә елап та алырга мөмкиннәр. Укытучыны аңлый, аның белән аралаша беләләр.

Бер төр характер сыйфатларын гына туплаган кешеләр сирәк очрый. Ә үзенә төрле характер билгеләрен туплаганнар белән эш алып бару тагын да кыенрак.

Балалар белән хезмәттәшлек итү демократик, гуманистик нигездә дусларча алып барылырга тиеш. Бу җиңел мәсьәлә түгел, әмма бик мөһим. Шуны гамәлгә ашырмыйча, уңышка ирешү мөмкин түгел. Шуңа күрә укучы характерын тәрбияләү, аңлауны һәм шәхес формалаштыруны укытучы үзенең төп педагогик бурычы итеп куярга тиеш.

Билгеле, бу эштә уңышка ирешүдә тулаем мәктәп эшчәнлеге, андагы эшлекле атмосфера да зур әһәмияткә ия. Укучы мәктәптә укыган елларында матур истәлекләр калдырырга тырыша, шулай ук күңеленә шифалы орлыклар чәчкән, вакытында кимчелекләрен бетерергә ярдәм иткән, түземлелек күрсәтеп, яхшы киңәшләр биргән укытучыларын онытмый.

Балаларга ышаныч белдерү, алар белән теге яки бу эш турында киңәшү белем һәм тәрбия бирүдә уңышка ирешергә ярдәм итә. Боларны истә тоткан укытучы балалар белән сөйләшкәндә: "Без сезнең белән бу эшне ахырынача эшләрбез", "Әлеге мәсьәлә турында син ничек уйлыйсың?", "Сыйныф сәгатен нинди темага үткәрергә икән?", "Бу эшне башкаруыңа ышанычым зур, чөнки син көтелмәгән хәлләрдә дә аптырап калмыйсың", "Син аңлы кеше, миңа бу эштә ярдәм итсәңче" кебек сүзләрне еш куллана. Хезмәттәшлек процессында укытучы укучының иптәшләре алдында абруен күтәрүгә нык игътибар итә. Укучы фикерләрен, мөстәкыйльлеген һәм инициативасын хуплау, аның белән сөйләшү үзара аңлашуга булыша. Американың күренекле психологларыннан берсе әйткәнчә, ышаныч белдерү – шәхеснең әхлакый сәламәтлеге билгесе. Башкаларга ышанмаучы кеше изге күңелле була алмый.

Кызганыч, без мәктәп тормышында еш кына боларның киресен күрәбез. Укытучы балага теләсә нинди сүзләр әйтә, көндәлегенә урынлы-урынсыз кисәтү сүзләре яза, әти-әнисен мәктәпкә чакырып сөйләшү белән яный. Моның нәтиҗәсе ачык: бала мәктәпкә йөрергә теләми, көндәлеген яшерә, укытучыны күрәсе килми. Психология фәнендә бу *дидактогения* дип атала.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: белем бирүдә хезмәттәшлек итү укучының яшенә дә бәйле. Башлангыч сыйныфта ул – баланың хәтерен, хисен һәм аңлау дәрәҗәсен; өлкән сыйныфларда исә логик фикерләүне һәм шәхеснең рухы ни дәрәҗәдә бай булуын истә тотып оештырыла. Балалар үскән саен, хезмәттәшлек эшлеклерәк була бара.

Болар һәммәсе укытучының шәхес үзенчәлекләренә, гомуми культурасына, балалар белән ни дәрәҗәдә аралаша алуына бәйле.

## 5.2. Вопросы для самоконтроля

1. В чем сущность профессионального самовоспитания учителя?

2. Назовите факторы, стимулирующие процесс профессионального самовоспитания учителя.

3. Назовите способы профессионального самовоспитания.

## 5.3. Задания для практики.

Попробуйте решить педагогическую задачу, с которой столкнулась одна английская учительница. Когда она вошла в класс, все дети громко хором пели старую английскую песню: «У старика Макдональда ферма, на ней живет корова. Му-му-му-му...» Эту песню можно было продолжать бесконечно, перечисляя всех животных, которые жили на ферме, и издавая соответствующие звуки.

Что сделали бы в этой ситуации вы?

Ознакомиться с текстом документа «Тема 5» , добавить вопросы для самоконтроля.

## 5.4. Глоссарий по теме 5

**Педагогическое сотрудничество** (team / collaborative teaching – преподавание в команде / сотрудничество в преподавании) – это технология обучения, подразумевающая взаимодействие группы преподавателей, нацеленное на повышение эффективности обучения. В более узком смысле термин описывает совместную работу двух или более преподавателей на аудиторном занятии, и именно это понимание является наиболее распространенным в сфере преподавания как в России, так и за рубежом

**Саморазвитие –** процесс активного, последовательного, прогрессивного и в целом необратимого качественного изменения психологического статуса личности. Саморазвитие возможно на определенной ступени возрастного развития, когда сформировались механизмы саморегуляции

**Самосовершенствование –** способность человека целенаправленно саморазвиваться, самовоспитываться, самообразовываться, ориентируясь на принятые нравственные нормы и идеал. Самосовершенствование возможно

только на основе развития духовных сил человека, нравственного сознания и через целенаправленную деятельность.

### 5.5. Использованные информационные ресурсы

http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор. РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php

## Тема 6. ПЕДАГОГ ХЕЗМӘТЕНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БИЛГЕЛӘҮ

**Аннотация.** Данная тема раскрывает содержание и структуру профессиональной компетентности педагога. Рассматриваются профессиональные умения учителя.

**Ключевые слова.** Компетентность, теоретическая готовность, практическая готовность.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### 6.1. Педагог хезмәтенең нәтиҗәлелеген билгеләү

Халык мәгарифендә хезмәткә түләү – иң җитди мәсьәләләрнең берсе. Мәгълүм булганча, укытучыларга хезмәт хакы эш стажына, белеменә, мактаулы исеменә карап билгеләнә.

Тырыш хезмәтләрен бәяләп, байтак укытучыларга Мактау грамоталары, орденнар да тапшыралар. Ләкин боларның хезмәт хакы күләменә тәэсире юк.

Укытучы хезмәте мәктәп тәкъдиме, аттестация комиссиясе әгъзалары фикере буенча бәяләнә. Әмма кайвакыт мактаулы исемнәр, югары категорияләр очраклы кешеләргә бирелә. Мәсәлән, хәтта чит илләрдә дә танылган новатор укытучылар С. Лысенкова һәм В. Шаталовка атказанган укытучы дигән исем киң җәмәгатьчелек таләбе белән генә бирелде.

Мәгълүм ки, аттестация үткәрүне демократияләштерергә тырышу да әлеге мәсьәләне уңай хәл итә алмый. Дөрес, комиссия әгъзалары фикере барлык педагогларга җиткерелә, һәм ул җыелышта тавыш бирү юлы белән раслана. Ә кайчакта исә педагогик совет утырышында бу мәсьәлә буенча тавыш бирү аттестация комиссиясе (бу сүзләрне администрация дип укырга да була) тәкъдименә төзәтмәләр дә кертергә мөмкинлек тудыра. Әлеге комиссия еш

кына укытучы куллана торган алым һәм методларны, ал арның нәтиҗәлелеген җентекләп өйрәнми, аның белем бирүенә һәм сыйныф җитәкчесе буларак алып барган эшенә тиешле бәя бирә алмый. Кайвакыт педсовет комиссия тарафыннан дәрес бәя алмаган укытучыны яклый. Әмма бу бик сирәк була. Еш кына укытучылар да үз хезмәттәшләренең эшчәнлеген дөрес бәяли алмыйлар. Әйтик, химия укытучысы чит тел яки физкультура укытучысының һөнәри осталыгын ничек дөрес билгели алсын ди инде? Гадәттә, мондый очракларда педагог хезмәтенә бәя җитәкчеләр әллә нигә бер кереп утырган дәрес нәтиҗәләренә, укучыларның сирәк-мирәк кенә әйткән фикерләренә нигезләнеп бирелә. Аттестация үткәргәндә бердәнбер таләп шул: укытучының балаларга ни дәрәҗәдә белем бирүе (балаларның белем дәрәҗәсе) һәм башка юнәлешләр буенча эшчәнлеге (кабинет җиһазлавы, фәнни-методик эштә катнашуы, үз белемен күтәрүе һ. б.) истә тотылырга тиеш.

Ә гомумән, укытучы хезмәтен дөрес бәяләү билгеләре (критерийлары) булуы мөмкинме соң?

"Педагог хезмәтенең нәтиҗәләре" дигән төшенчә бик киң мәгънәгә ия, һәм ул шуңа күрә эчке каршылык тудыра. Әйтик, берәү мәктәпне "5" ле билгесенә генә тәмамлый. Мөстәкыйль тормыш юлына аяк баскач, ул җинаять кыла. Ә икенче бала "3" легә генә укыса да чын кеше булып үсә. Бу балаларның кайсын укыткан укытучыны яхшы мөгаллим дип билгеләргә мөмкин? Әлеге эштә нинди методика кулланырга?

Бу уңайдан чит илләр тәҗрибәсенә күз салыйк: алга киткән капиталистик илләрдә укытучы хезмәтен бөтенләй башкача бәялиләр. Ул укытучыны башкаларга бәйлелектән коткара, шәхес буларак үсәргә, балалардан да шәхес тәрбияләргә ярдәм итә. Икенче яктан, мондый система аны белемен тулыландыруга, осталыгын арттыруга этәрә.

Нинди гаҗәеп система соң ул? Аның нигезендә эшләгәндә югарыда искә алынган каршылыклар ничек хәл ителә?

Мәктәптә, төгәлрәге белем бирү системасында, нигездә, укытучы хезмәте нәтиҗәләренә тулысынча дөрес бәя биреп булмый. (Моның өчен бик күп

мәгълүмат, белешмә тупларга кирәк.) Педагог эшчәнлегенә бәя бирү белгечләрен булдыру да мөмкин түгел. Шуңа күрә башка илләрдә аларның эшчәнлек көче, тырышлыгы бәяләнә. Ул система, нинди дә булса уку йортын тәмамлагач, кеше диплом алганда бездә дә бераз чагылыш таба.

Әлеге системаның нигезен нәрсә тәшкил итә соң? Югары уку йортын тәмамлаган яшь белгечкә диплом тапшырганда аңа алдан ук зур өметләр баглана. Әле бу вакытта аның ничек эшләячәге, нәрсәгә ирешәчәге билгеле булмый. Әмма аңа белгечлеге буенча эшләү хокукын бирә торган диплом тапшырыла.

Мәгълүм ки, бу хокук аңа уку йортында билгеле бер һөнәр буенча тиешле белем алган өчен бирелә. Аның ни дәрәҗәдә белем туплавы имтиханнарда ачыклана. Шулай да уку йортында алган белемгә генә карап кешенең нинди белгеч булачагын әйтүе кыен. Моны бары тик эш нәтиҗәләренә карап кына бәяләргә була.

Үсеш ягыннан алга киткән илләрдә укытучылар квалификация имтиханнары тапшыралар. Ә безнең мәгариф системасында ул каралмаган. Педагогларыбыз имтихан урынына аттестация үтәләр. Бу бер яктан аклана да. Мәктәптә эшли башлагач, яшь белгечкә хезмәттәшләре, җитәкчеләр ярдәм итә, аның дәресләренә кереп утыралар, бәя бирәләр. Администрация тарафыннан мондый тикшерү системасы совет власте урнашкан елларда кертелгән иде. Бу ул вакыт өчен үзен аклагандыр да. Чөнки җәмгыять яңа төр шәхес – совет кешесен тәрбияләүне максат итеп куйган иде. Әлеге идеологик эш, партия җитәкчелегендәге кебек үк, партия әмерен төгәл үтәүче булды. Аннары методик эштә дә шундый ук алымнар кулланылды. Педагогик белемле укытучылар аз булган чорда болай эшләү зарурлыгы булгандыр. Хәзер исә яшь педагоглар гына администрация ярдәменә мохтаҗ.

Франция мәктәпләрендә, мәсәлән, беркем дә дипломлы укытучы дәресенә кереп утыру, аның эшен тикшерү хокукына ия түгел. Ул, тиешле имтиханнар биреп, үзенең укытучы булып эшли алуын исбатлаган инде. Ә аның белгечлеге буенча хезмәте ничек бәяләнә соң? Гаҗәпкә каршы, ул тагын имтихан тотарга

тиеш була. Квалификация имтиханы (тест) тапшырганнан соң, белгечкә билгеле бер категория бирелә. Шуның нигезендә аның хезмәт хакы да арттырыла. Шулай итеп, Франциядә укытучыларның эш хакы хезмәт нәтиҗәләрен тикшерү-өйрәнү нәтиҗәсендә түгел, ә бәлки билгеле бер категориягә имтихан тапшыру нигезендә арттырыла. Бу – кыен эш. Хезмәт хакын күбрәк алырга теләүчеләр күп укыйлар, эзләнәләр, белемнәрен баеталар, педагогик осталыкка өйрәнәләр. Алар, имтихан тотканда, үзләренең ни дәрәҗәдә белемле булуларын, аны ничек куллануларын күрсәтергә тиеш.

Әлеге система, безнең мәктәпләрдә дә кулланылса, укытучыны үз белемен даими күтәрергә, иҗади эшләүгә этәрер иде. Бәлки бу фикергә каршы: "Белемле укытучы һәрвакытта да яхшы эшләмәскә дә мөмкин", - дип әйтүчеләр булыр. Алар да хаклы. Әмма шуны да истә тотыйк: киң карашлы, тирән белемле, зыялы укытучылар арасында начар эшләүчеләрне табуы кыен. Фән казанышлары, алдынгы методика, иҗади эшләүчеләр тәҗрибәсе белән танышып баручы педагогларның эш нәтиҗәләре дә әйбәт була.

Квалификация имтиханнары үткәрү укытучы хезмәтенә дөрес бәя бирергә ярдәм итә. Башка илләрдә исә мондый алым эшчән-лекнең барлык тармакларында да кулланыла. АКШта, мәсәлән, барлык мәгариф системасына хезмәт күрсәтү максатыннан, тестлар әзерләү буенча милли үзәк төзелгән.

Укытучы хезмәтен квалификация имтиханы ярдәмендә бәяләү мәсьәләсе Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгында да карала. Әмма моның белән шөгыльләнүчеләр, категорияләр биргәндә, квалификация имтиханнары һәм хезмәт нәтиҗәләрен дә искә алуны күз алдында тоталар. Бер караганда, аларның фикерләре урынлы кебек, һәр яхшы белгеч яхшы методист була алмый. Әмма эшнең соңгы нәтиҗәләрен бәяләү аның критерийларын һәм ысулларын табуны таләп итә.

Алар нинди булырга тиеш соң? Укытучының нәтиҗәле эшләвен югары уку йортына кергән укучылар санына карап бәяләргәме? Ә фәннәр тирәнтен өйрәтелә торган сыйныфларда эшләүчеләр хезмәтен ничек бәяләргә? Алар да белем алучыларның һәрберсе югары һәм махсус урта уку йортларына укырга

керә бит. Әмма, мәктәптә югары квалификацияле укытучылар булса да, кайбер җитәкчеләр фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфлары ачарга ашкынып тормыйлар. Азкомплектлы мәктәпләрдә исә аларны ачу мөмкинлеге юк. Мондый очракларда инде тирән белемле, зыялы укытучылар гаепле түгел.

Укытучы хезмәтен район методик берләшмәсе биргән мәгълүматларга карап та бәяләп булмый. Чөнки методик берләшмә әгъзалары укытучының берике дәресенә генә кереп утыра алалар. Шул дәресләрнең эчтәлегенә карап кына педагог хезмәте дөрес бәяләнә алмый.

Шулай итеп, укытучы хезмәте нәтиҗәләрен (укытучының белемле, зыялылыгы, балаларга тирән белем бирү алымнарына ия булуы, үз белемен күтәрүе һ. б.) бәяләү алымнары эшләнмәгән әле.

Мәгариф хезмәткәрләре аны булдыру турында ныклап уйланырга тиеш. Хәзерге вакытта мәктәптә укытучының үз белемен күтәрүе, педагогика, психология, методиканы, үз фәнен өйрәнү, гомумән, илһамланып эшләве өчен тиешле шартлар булдырылырга тиеш. Болар исә аның гомуми зыялылык дәрәҗәсен арттырырга, белемен тирәнәйтергә, эштә югары нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итәр.

### 6.2. Вопросы для самоконтроля

1. В чем находит выражение профессиональной компетентность, какова ее структура?

2. Раскройте содержание теоретической готовности учителя.

3. Раскройте содержание практической готовности учителя.

### 6.3. Задания для практики

Составить таблицу в которой будет отражен ответ на следующий вопрос: Что объединяет и чем отличаются педагогические способности от общих способностей личности?

Ознакомиться с текстом документа «Тема 6» , добавить вопросы для самоконтроля.

### 6.4. Глоссарий по теме 6

**Актуализация** – воспроизведение имеющихся у человека знаний, умений, навыков, различных форм поведения и эмоционального состояния, перевод их из потенциального состояния в актуальное действие.

**Антиципация** – представление предмета, явления, результата действия и т.п. в сознании человека еще до того, как они будут реально восприняты или осуществлены.

**Дедукция** – вывод по правилам логики; цепь умозаключений, звенья которой связаны отношением логического следования.

**Индукция** – логическое рассуждение, двигающееся от утверждений менее общего характера к утверждению более общего характера.

### 6.5. Использованные информационные ресурсы

http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор. РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php

## Тема 7. МӘГАРИФ ҮСЕШЕНЕҢ ТӨП ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация.** Данная тема раскрывает объект, предмет, функции педагогики. Рассматриваются категориальный аппарат педагогической науки.

**Ключевые слова.** Объект, предмет, функция, воспитание, обучение, образование, развитие.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### 7.1. Мәгариф үсешенең төп үзенчәлекләре

Хәзерге чорда җәмгыять белән бергә халык мәгарифе дә зур үзгәрешләр кичерә. Соңгы елларда белемнең сыйфатын күтәрүнең бик күп юнәлешләре барлыкка килде. Шулар арасында бишесен аерым күрсәтеп үтик:

– мәктәпнең бала шәхесенә методик һәм фәнни яктан тәэсирен үзгәртүе;

– һәркемгә мәҗбүри булган белем нигезенең база эчтәлеген билгеләү;

– билгеле бер белемнәргә ия булу өчен педагогик шартлар булдыру;

– укыту методларын активлаштыру;

– укытучының профессиональ осталыгын үстерү. Укытучының профессиональ осталыгын үстерү – болар арасында иң мөһим юнәлеш. Чөнки аны гамәлгә ашырмыйча, башкаларын үтәп булмый.

Шуңа күрә югары квалификацияле укытучы, тәрбиячеләр һәм укыту-тәрбия учреждениеләре өчен башка белгечләр әзерләү гаять мөһим мәсьәлә булып тора.

Соңгы елларда республикада педагогик кадрлар берничә югары педагогика уку йортында, ун педагогика колледжында, ике индустриаль-педагогика техникумында әзерләнә. Казанда Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү институты һәм Чаллыда өзлексез белем бирү институты эшли.

Һәр елны гомуми белем бирү мәктәпләренә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбияләнә торган һ.б. укыту-тәрбия учреждениеләренә йөзләречә яшь педагог эшкә җибәрелә. Башлангыч мәктәп, музыка һәм җыр, сынлы сәнгать укытучыларына, мәктәпкәчә учреждениеләр тәрбиячеләренә булган ихтыяҗ тулысынча канәгатьләндерелә.

Укытучыларны яңа юнәлешләр нигезендә әзерләү гамәлгә ашырыла. Алабуга педагогика институтында, мәсәлән, татар теле һәм әдәбияты, чит тел; рус теле һәм әдәбияты, инглиз теле; биология (яки химия) һәм авыл хуҗалыгы производствосы нигезләре белгечлекләре; Чаллы педагогика институтында география, татар теле һәм әдәбияты (рус һәм татар мәктәпләре өчен) белгечлекләре буенча кадрлар әзерләнә, татар мәктәпләрендә эшләү өчен химия, биология, география, математика, физика, музыка һәм җыр укытучылары әзерләнә башлады.

Республикабыз педагогика колледжларында һәм училищеларында укучылар башлангыч сыйныф, җыр, рәсем, хезмәт, физкультура һәм мәктәпкәчә балалар учреждениеләре тәрбиячеләре белгечлекләренә ия булалар. Алар икенче белгечлек тә үзләштерә: озайтылган көн художество хезмәте, рус мәктәпләренең башлангыч сыйныфларында һәм мәктәпкәчә учреждениеләрдә татар теле укытучысы, балалар бакчасында физик тәрбия җитәкчесе, музыкант эшләренә өйрәнәләр.

Педучилищеларда милли мәктәпләр һәм мәктәпкәчә учреждениеләр өчен педагогик кадрлар әзерләү программасы да төзелде. Шуның нигезендә Бөгелмә, Чаллы, Түбән Кама педучилищесында – чуваш мәктәпләре һәм балалар бакчалары өчен укытучылар, тәрбиячеләр, ә Лениногорскида татар мәктәпләре өчен музыка һәм җыр укытучылары әзерләнә.

Педагогика училищеларындагы 9 мең укучының 5 меңе татар бүлекләрендә белем ала.

Республикада "Татарстан педагогика училищелары" дигән программа да төзелде. Ул, безнең укыту-тәрбия учреждениеләрендә төрле юнәлештә эшли

торган югары квалификацияле кадрлар әзерләүне максат итеп куеп, махсус урта белем бирүне тамырдан үзгәртүне күздә тота.

Шушы программаны үтәү йөзеннән һәм татар теле укытучыларына һәм балалар бакчаларындагы татар төркемнәрендә тәрбиячеләргә ихтыяҗ артуын искә алып, республикабызда иң алдынгы Арча, Минзәлә, Чаллы педучилищелары һәм Казандагы 1 нче педучилище педагогика колледжы итеп үзгәртелде. Аларда татар мәктәпләре өчен музыка һәм җыр; тулы булмаган урта мәктәп өчен – башлангыч сыйныф, татар теле һәм әдәбияты; укыту рус телендә алып барыла торган мәктәп өчен – башлангыч сыйныф һәм татар теле; тулы булмаган урта мәктәп өчен рус теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләнә. Казан дәүләт гуманитар институты ачылды. Анда шулай ук ана теле һәм әдәбияты укытучысы булырга теләгән егетләр һәм кызлар белем ала.

Аларның максаты – тирән белемле, зыялы укытучылар әзерләү.

Яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә гадәти булмаган алымнар эзләү яңа төрдәге мәктәпләр: мәктәп-комплекслар, мәктәп-гимназияләр, лицей, тәҗрибә мәктәпләре барлыкка килүгә сәбәпче булды. Хәзер безнең республикада андый уку йортларының саны 100 дән артып китә. Алардагы классларда балалар саны азрак булу, укыту планнарына яңа, шул исәптән интегральләштерелгән фәннәр кертелү, кайбер фәннәрне тирәнтен өйрәнү класслары, мәктәпләре ачылу укытучыларга ихтыяҗны тагын да арттыра. Яңа төр уку йортларына математика, физика һәм информатика, латин, төрек, гарәп телләре, психология, икътисад, маркетинг, менеджмент, дөнья культурасы тарихы укытучылары кирәк. Татар мәктәпләре өчен кадрлар, бигрәк тә чит телләр, Татарстан тарихы һәм мәдәнияте укытучылары, елдан-ел күбрәк кирәк булачак.

Күренгәнчә, мәгарифебезне аякка бастыру өчен бик күп эшлисе бар әле.

Мәгълүм ки, бүгенге көндә укытучылар әзерләүнең эчтәлеге мәктәпне канәгатьләндерми, чөнки ул фән белгече дә һәм яшь буынны тәрбияләүче дә булырга тиешле чын педагог формалаштыра алмый. Педагог булырга әзерләнүчеләр һәм уку йортын тәмамлап эшләүче педагоглар фәнни һәм һөнәри

белемнәргә ия булырга, җәмгыять һәм фән үсешен алдан күрә, сизә белергә тиеш.

Әмма югары белемле укытучылар халык хуҗалыгында эшләүче башка белгечлекләргә караганда күбрәк булсалар да (республикада төп фән укытучыларының 95 проценты – югары белемле), алар белем дәрәҗәсе буенча башка белгечләрдән бик нык калышалар. Ә бит мондый хәл җәмгыять үсешенә киртә булып тора. Укытучының тиешле белемгә ия булмавы нәтиҗәсендә бик күп яшьләр авыр язмышка дучар була. Бу фикергә каршы педагогик уку йортлары вәкилләре: "Мәктәп балаларга тиешле белем һәм тәрбия бирми. Шул сәбәпле институт, училищеларда тиешле дәрәҗәдә белем алмаган кешеләр укый. Алар, уку йортын тәмамлагач бик тырышып эшләсәләр дә, уртача укытучы гына булып калалар", - дип әйтерләр.

Белемсез укытучы булачак студентка тиешле белем бирә алмый. Ә югары уку йортына кергән белемсез студент уртача яки уртачадан түбән дәрәҗәдә эшләүче педагог була. Бу бәладән ничек котылырга соң? Аннан арыну юлы бер генә: педагогик уку йортларына сәләтле яшьләрне кабул итәргә, егетләргә өстенлек бирергә кирәк.

Кадрлар мәсьәләсен хәл итүдә һөнәр юнәлеше бирү һәм укытучы һөнәренә сәләтле кешеләр генә сайлау зур әһәмияткә ия. Әмма моңа хәзергә әллә ни игътибар ителми. Дөрес, моннан берничә еллар элек Казан, Чаллы шәһәрләре, Лаеш, Октябрь, Аксубай, Түбән Кама районнары мәктәпләрендә педагогик класслар ачылган иде. Соңгы елларда Кукмара районының Зур Сэрдек, Лаеш районының Никольский, Казанның 11 нче, 30 нчы һәм 52 нче мәктәпләрендә педагогик сыйныф ачылды. Чаллыдагы 35 нче татар гимназиясе дә шул юнәлештә эшли. Әмма аларның эшчәнлеген нәтиҗәле оештырганда, моңа югары уку йортлары укытучыларын тартканда гына ирешергә мөмкин.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, булачак укытучыны мәктәптә укыганда ук әзерләү өчен мондый эшләр башкарылырга тиеш:

– шәхеснең педагог һөнәренә, шул белгечлек буенча укырга яраклылыгын ачыклау;

– укучыларга алдан ук һөнәр юнәлеше бирү, педагог һөнәренә сәләтле балаларны сайлап алу һәм аларны фәнни-гамәли әзерләү;

– сайланып алынган яшьләрне институтка кабул итү өчен шартлар булдыру һәм аларның югары уку йортлары шартларына фәнни һәм гамәли яктан ияләшүе.

Моннан күренгәнчә, яшьләрне педагог һөнәренә әзерләү өчен бик зур тырышлык сорала. Югары уку йортлары укытучыларының педагогик сыйныфларда педагогика һәм психологиядән лекция укулары гына җитми. Булачак студентларга педагогик белем бирү концепциясе, укыту планнары һәм программалары, методик кулланмалар, педагогик уку йортларына сайлап алу методикасы, диагностика карталары, тестлар, социологик тикшеренү һәм медицина тикшеренүләре үткәрү кирәк.

Башкача әйткәндә, укучыларны педагогик уку йортына керергә әзерләү өчен укыту-фәнни-педагогик комплекслар, педагогик факультетлар булдыру сорала.

Мәктәп укытучыларга җитди дәгъва белдерә. Яшь укытучылар балалар белән тәрбия эше алын баруга, укучылар һәм ата-аналар белән аралашуга әзер түгел. Алар укыту-тәрбия эшендә төрле-төрле алымнар куллана, үз эшләренә анализ ясый, дәрес планы төзи алмый, педагогика фәне казанышлары, новатор укытучылар, иҗади эшләүчеләр тәҗрибәсе белән таныш түгел. Үз белгечлекләре буенча да белемнәре җитенкерәми. Югары уку йорты киләчәк мәктәбе өчен кадрлар әзерләп чыгарырга тиеш.

Гомуми белем бирү мәктәбен үзгәртеп кору укытуны интегральләштерү һәм дифференциацияләү гамәлгә ашыру белән тыгыз бәйләнгән. Аларның икесе дә укучыларның белемнәрен тирәнәйтүгә хезмәт итә. Бу принциплар фәнни яктан бик үк үстерелмәсә дә, интегральләштерү һәм дифференциацияләү гамәлгә ашырыла торган мәктәпләр байтак инде.

Яңа төр мәктәпләр һәм класслар өчен сәләтле укытучылар әзерләү мөһим мәсьәлә булып тора. Шуны бөтен тулылыгы белән аңлап, кайбер БДБ илләрендәге югары уку йортларында сәләтле студентларны эзләп табу һәм

аларның актив иҗади эшчәнлеген хуплау максатыннан индивидуаль программа төзелгән һәм шул нигездә эш башланган.

Укытучы, үз фәне буенча төпле белем туплау белән генә чикләнмичә, аны балаларга бирә белергә, белем бирү технологиясенә ия булырга, моңа ирешү өчен психология, педагогика, методиканы тирәнтен өйрәнергә, шулар нигезендә укучыларны үзе укыта торган фән белән кызыксындыра белергә тиеш. Шуңа күрә студентлар югары уку йортында укыганда педагогика, психологиядән тирән белем алсыннар, фәннәрне укытканда аны кулланырга өйрәнсеннәр. Яшь буында кешелеклелек сыйфатлары, тарихыбызны, әдәбиятыбызны ныгытып өйрәнү теләге тәрбияләү дә мөһим мәсьәлә.

Педагогик җәмәгатьчелек теләген искә алып, өзлексез белем бирү курсы, эксперименталь эш методикасы һәм техникасы, аны оештыру, профессиональ педагогика, халык педагогикасы, психология, физиология, философия, мәдәният тарихы, фәнни һәм гамәли этика курслары эшчәнлеген киңәйтү, укыту планнарына яңа фәннәр, сәяси, икътисади, хокукый темаларга лекцияләр циклы кертү сорала.

Әлбәттә, алда куелган бурычларны гамәлгә ашыру өчен фәнни-педагогик кадрларның уртак тырышлыгы, мәгариф мәсьәләләре белән тирәнтен кызыксынуы, бергәләп, үзара ярдәмләшеп эшләве кирәк.

### 7.2. Вопросы для самоконтроля

1. В чем сущность развития образования?
2. Как соотносятся воспитание и развитие?
3. Назовите объект и предмет педагогики.

### 7.3. Задания для практики

Составить таблицу в которой будет отражен ответ на следующий вопрос: В чем отличие научного педагогического знания от житейского?

Ознакомиться с текстом документа «Тема 7» , добавить вопросы для самоконтроля.

### 7.4. Глоссарий по теме 7

**Объект науки** – определенная область реальности, на которую направлен процесс научного познания.

**Предмет науки** – часть объекта, определённый его аспект, исследуемый в каком-либо конкретном случае.

### 7.5. Использованные информационные ресурсы


http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор. РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php

## Тема 8. УКЫТУ ПРОЦЕССЫ ҺӘМ УКЫТУЧЫ ШӘХЕСЕ

**Аннотация.** Данная тема раскрывает значение методологии и методов педагогического исследования. Рассматривается несколько групп методов исследования.

**Ключевые слова.** Личность, обучение, учение, воспитание.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### 8.1. Укыту процессы һәм укытучы шәхесе

Укыту процессының структурасын караган вакытта, аның төзелешен, төп компонентларын һәм алар арасындагы бәйләнешне ачыклау мөһим. Укыту процессында бер яктан – укытучы, икенче яктан укучылар катнашканлыктан, ягъни ике якның эшчәнлеген характерлаганлыктан, укыту процессы икеяклы характерда дибез. Ул укытучы һәм укучылар арасында (берәү яки коллектив) билгеле бер шартларда (укыту, мораль-психологик һәм эстетик) уза торган эш-гамәлләрне күз алдында тота.

Укыту процессы (иң киң мәгънәдә караганда) үзара бәйләнгән ике процесстан – *укытудан* һәм *укудан* тора.

Укыту укытучы һәм укучының бер үк вакыттагы эшчәнлегеннән, аларның үзара дидактик йогынтысыннан башка мөмкин түгел. Укытучы белем бирүгә никадәр актив омтылса да, әгәр бу вакытта укучыларның белемнәрне үзләштерүгә актив эшчәнлекләре оештырылмаса, әгәр укытучы дәлилләү тудырмаса һәм андый эшчәнлекне оештыруны тәэмин итмәсә, ул вакытта укыту процессы бармый – үзара дидактик йогынты булмый. Шуңа күрә укыту процессында укытучының укучыга йогынтысы гына түгел, ә аларның үзара йогынтысы килеп чыга. Укучы белән педагогның шәхси йогынтыларының

бердәмлеге эчке чагылыш булып бара. Бу йогынтылар укучының белемнәрне үзләштерүдә үз тырышлыгы барлыкка килү белән, осталык, күнекмә, тәрбиялелек һәм кызыксынучанлыкның аерым элементлары белән тормышка аша.

Укытучы белән укучының үзара йогынтысы турыдан-туры да, капмакаршы да булырга мөмкин. Турыдан-туры йогынты вакытында укытучы һәм укучы укыту бурычларын бергәләп тормышка ашыралар. Капма-каршы йогынты вакытында укучылар укытучы тарафыннан алдан бирелгән бирем һәм инструкцияләрне үтиләр. Укыту процессы бу вакытта укытучыдан башка да барырга мөмкин. Мәсәлән, укучылар уку эшчәнлегенең яңа чараларын үзлекләреннән өйрәнәләр, укытучы биременнән һәм инструкциясеннән башка иҗади мәсьәләләр чишәләр. Укыту процессы, һичшиксез, уку процессының актив булуын күздә тота.

Шул ук вакытта укыту процессы дәрес бирү һәм өйрәнү процессының механик суммасы да түгел. Бу асылда яңа, бербөтен күренеш. Алар үзара дидактик йогынтыны аның төрле формаларында яктырталар. Бу процессның бербөтенлеге укыту һәм уку максатларының гомумилегендә, укытуның укудан башка яши алмавында күренә.

## 8.2. Укыту процессында аралашу

Укыту процессы – танып белү характерындагы процесс кына түгел, ә укытучы белән укучының аралашу процессы да. Укыту процессында аралашу укуга омтылыш һәм теләп укуга уңай мөнәсәбәт формалашуга, актив уку өчен уңайлы мораль-психологик шартлар тудыруга бик зур йогынты ясый.

Укытучының үз предметын яратуы, эшендәге оешканлык, укучылар белән мөгамәләсендә тактлылык, укуда ал арга үз вакытында ярдәм итүе, уңышларын бәяләгәндә гадел, катлаулы ситуацияләрдә сабыр булуы – болар һәммәсе үзләштерү процессына бик көчле ярдәм итә, укучыларда укытучыга охшау омтылышы уята. Оста һәм белеп аралашу нәтиҗәсендә укытуның тәрбияви көче шактый арта.

Әгәр укытучы игътибарны укыту эшчәнлеге белән идарә итүгә генә туплап, бу вакытта дөрес аралашу стилен тудыра алмаса, ул чагында үзара йогынтының нәтиҗәсе җитәрлек булмый. Уңайлы аралашу җирлеге тудырылып та, укыту эшчәнлеге оештырылмаган булса, тырышлык шулай ук нәтиҗәсез була.

Менә шуның өчен укытуның төп асылын ачканда танып белү һәм аралашуның бердәмлеген күрергә кирәк.

### 8.3. Укытуда мохит йогынтысының роле

Белем алу, тәрбия һәм шәхеснең үсеше укыту һәм тәрбия процессында гына түгел, бәлки мохитнең, массакүләм мәгълүмат чараларының, җәмгыятькә файдалы хезмәт, спорт, уен һ.б. укудан тыш эшләрнең йогынтысында да тормышка ашырыла. Махсус оештырылган укыту һәм тәрбия бу социаль фактор һәм шартларны исәпкә алырга һәм файдаланырга тиеш, чөнки ал арның йогынтысы һаман саен киңрәк, күпкырлырак, нәтиҗәлерәк һәм күп очракта ихтыярсызрак була бара.

### 8.4. Укыту процессының структурасы

Хәзер инде дидактик үзара тәэсир итешүнең үсешен ачыграк итеп сурәтләү, ягъни укыту процессы структурасын тирәнрәк итеп карап китү мөһим.

"Процесс" төшенчәсе нинди дә булса күренешнең үсешен – берсе артыннан икенчесе килә торган даими, эзлекле алышынып торуын чагылдыра. Дидактик үзара тәэсир итешү – бик тиз хәл ителә торган, үзенә генә хас өлешләре булган процесс ул. Укыту процессының состав өлешләрен якынча бербөтен итеп күз алдына китерергә кирәк: укытуның максаты, укыту-тәрбия процессының эчтәлеге, укыту формалары, метод һәм алымнары.

**Укыту процессының максатчанлыгы** өйрәнелә торган тема, бүлек яки бөтен бер уку фәненең максатын һәм бурычларын укытучы һәм укучыларның ал арны ничек кабул итүе ул. Укыту максаты мәктәп алдына җәмгыять тарафыннан куелган бурычлар белән билгеләнә. Бу максат шулай ук халык

мәгарифе турындагы законнарда һәм башка хөкүмәт документларында чагылыш таба.

Укыту процессының конкрет циклында укытуның максаты һәм бурычлары программа таләпләре нигезендә билгеләнә. Бу вакытта сыйныф үзенчәлеге, әзерлек дәрәҗәсе, белеме, тәрбиялелеге һәм укучыларның кызыксынучанлыгы, шулай ук укытучының үзенең мөмкинлеге, кабинетның җиһазланышы һ.б. исәпкә алына.

**Укытуның эчтәлеге** уку планы, уку программалары һәм фәннәр буенча дәреслекләр белән билгеләнә. Аерым фәннәрдән кайбер темаларның эчтәлеге, укучыларның кызыксынуын, әзерлек дәрәҗәсен, мәктәпнең социаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, укытучы тарафыннан конкретлаштырыла.

**Укытуның методлары** аның процессуаль асылын яктырта. Бары тик укытучы һәм укучыларның бер-берсенә бәйләнгән эшчәнлегендә, аларның үзара тәэсир итешүендә генә кешелекнең киң социаль тәҗрибәсе укучылар тарафыннан үзләштерелә, һәр укыту методы билгеле бер алымнар, уку һәм укытуны оештыру формалары һәм чаралары ярдәмендә башкарыла.

Укыту алдында торган бурычларны хәл итү барышына, уку операцияләре үтәлешенең дөреслегенә, алынган җавапларның төгәллегенә укучыларның үзконтроль ясавы күздә тотыла. Контроль телдән, язма, лаборатор һәм башка практик эшләр, сораштыру, зачет һәм имтиханнар ярдәмендә башкарыла. Үзконтроль укучыларның үз-үзләрен тикшереп карауларын күздә тота. Алар өйрәнелгән материалның үзләштерелү дәрәҗәсен, кире элемтә ярдәмендә күнегүләрнең дөрес үтәлешен, мәсьәләләргә алынган җавапларның тормышчан чынбарлыгын мөстәкыйль бәялиләр. Контроль һәм үзконтроль уку процессында кире элемтәнең тормышка ашуын тәэмин итә. Укытучы материалның укучылар тарафыннан үзләштерелү дәрәҗәсе, укыту бурычын этаплап хәл итүнең сыйфаты һәм типик җитешсезлекләр турында мәгълүмат ала.

Кире элемтә уку процессына төзәтмәләр кертү зарурлыгын китереп чыгара. Бу – укыту методларына, формаларына үзгәрешләр кертү, ал арны бирелгән ситуациягә якын китерү дигән сүз.

Төзәтү (коррекция) укытучы тарафыннан гына түгел, укучылар тарафыннан да үткәрелә (үз эшчәнлегеңне үзең җайга салу, ялгышлар өстендә эшләү, кыенлык тудырган сорауларны кабатлау һ.б.).

Укыту процессы педагоглар һәм укучыларның укыту процессы нәтиҗәләренә үзлектән бәя бирүен күз алдында тота. Ул ирешелгән нәтиҗәләрнең укыту-тәрбия проблемалары алдына куелган бурычларга туры килү-килмәвен, читкә тайпылу сәбәпләрен ачыклауны, шулай ук белем һәм күнекмәләрдә беленгән бушлыкларны исәпкә алу зарурлыгын тикшерә.

Укыту процессының барлык компонентларын үзара бәйләнештә карарга кирәк. Укытуның максаты һәм эчтәлеге укытуны оештыруның һәм стимуллаштыруның аерым методларын, чараларын таләп итә. Ниһаять, укыту процессының барлык компонентларының максатлы җыелмасы билгеле бер нәтиҗәне тәэмин итә.

Укыту бурычларының үзенчәлегенә, укучыларның мөмкинлекләренә, аларның укуга мөнәсәбәтләренә бәйле рәвештә теге яки бу компонентлар төрле дәрәҗәдә кулланыла, ә кайвакытта, аерым бер шартларда, бөтенләй төшеп тә калырга мөмкин. Шулай итеп, укыту процессын планлаштыруга һәм аны тормышка ашыруга иҗади якын килергә кирәк, аларны конкрет ситуацияләргә бәйсез рәвештә кулланырга ярамый.

### 8.5. Укыту процессында укытучы эшчәнлеге

Укыту процессының асылын ача барып, без анда укыту белән укуның, ягъни укытучы һәм укучылар эшчәнлегенең органик кушылганын күрдек. Укытучы эшчәнлегенең төп бурычы – укучыларның яңа материалны үзләштергәндәге актив һәм аңлы эшчәнлеге белән идарә итү. Шуңа күрә укыту процессында җитәкчелек роле укытучыда була. Ләкин укыту процессы укучыларның актив эшчәнлегеннән башка мөмкин түгел.

Шуны күрсәтеп китү әһәмиятле: элек, укыту процессына характеристика биргәндә, укытучы эшчәнлеген укучыларга белем һәм осталыкның билгеле бер суммасын бирү дип кенә караганнар. Бу күзлектән караганда, укытучы укытуның актив субъекты, ә укучы бары тик аның пассив объекты булып саналган.

Хәзерге дидактика укытучыны укучыларның яңа белем һәм осталыклар үзләштерүдәге актив эшчәнлеген оештыручы дип саный.

Теләсә нинди идарә итү эшчәнлеге циклына планлаштыру, оештыру, стимуллаштыру, агымдагы контроль, коррекция һәм эшнең нәтиҗәләренә анализ кебек элементлар керә. Менә бу элементлар укытучы эшчәнлегенә дә хас.

Укытучы үзенең **планлаштыру эшчәнлеген** календарь-тематик һәм дәрес планнары төзегәндә тормышка ашыра. Календарь-тематик план үрнәкләре методик журналларда басыла. Укытучы, сыйныфның һәм мәктәпнең үзенчәлегеннән чыгып, ал арга төзәтмәләр кертә ала. Дәрес планнары төзегәндә, шул предметка караган махсус кулланмалардан да файдаланырга мөмкин.

Бу кулланмаларда эчтәлекнең әһәмиятле һәм кыен элементлары аерып күрсәтелә; ныгыту, кабатлау, өйдә эшләү өчен биремнәр тәкъдим ителә. Мондый методик кулланмалар дәрес планнары төзегәндә укытучының вакытына сизелерлек экономия ясый һәм мөмкин булган берничә варианттан бу сыйныфка иң кулаен сайлап алырга булыша.

Хәзерге дидактика барлык укытучыларга да дәрес планының стандарт формасын файдаланырга тәкъдим итми. Планның тексты укытучының педагогик тәҗрибәсенә бәйләнгән. Яшь, әле эшли генә башлаган укытучыларга үз эшләренең беренче этабында дәрес планнарын җентекләп төзергә киңәш ителә. Дәреснең максатын күрсәткәндә уку, тәрбия һәм акыл сәләтен үстерү бурычларын берләштерергә; өй эшен тикшергәндә кирәк булачак төп сорауларны кыскача язып куярга; яңа материалны өйрәнү планын, белемнәрне ныгыту һәм куллану күнегүләренең номерларын, өйгә биреләчәк эшләрнең

эчтәлеген, җиһазлау һәм дәрес материалын аңлатканда кулланылган әдәбиятны күрсәтеп язарга кирәк.

Тәҗрибәле укытучыларга дәреснең бурычын, максатын болай җентекләп язу кирәкми. Аерым фәнне өйрәнүгә караган методик кулланмаларда алар бирелгән. Яңа материалны өйрәнү планы да бик үк җентекле булмаса да ярый. Бу, билгеле, стажлы укытучыларга өстәмә таләпләр куярга ярамый дигән сүз түгел.

Шулай итеп, дәресләрне планлаштыру укытучының педагогик осталыгын күтәрү максатына һәм аларга практик ярдәм күрсәтүгә хезмәт итәргә тиеш. Болар бөтенесе дә дәресләрне планлаштыруга иҗади якын килүне таләп итә. Катлаулы темаларны өйрәнгәндә, аның алдагы тема белән бәйләнеше булмаса, дәресне турыдан-туры яңа материалны өйрәнүдән башларга мөмкин, һәр дәрестә дә укытучы материалны үзе сөйләми. Гади темаларны китаптан укучыларның үзләренә дәрестә өйрәнергә тапшырып була. Дәресне планлаштыруга болай якын килү шуның белән кыйммәтле: ул уку эшенең структурасын төрләндерә, укучыларның укуга кызыксынуларын арттыра.

Билгеләнгән планны үтәү буенча укыту эшен оештыру әзерлек һәм башкару этапларына бүленә. Дәрескә әзерләнгәндә укытучы, мөмкинлекләрдән чыгып, түбәндәгеләрне эшли:

– кирәкле техник чаралар, күрсәтмә әсбаплар, дидактик һәм тарату материалларын әзерли;

– тәҗрибәләрне алдан үткәреп карый, диафильмнар күрсәткәндә кыенлыклар килеп чыкмасын өчен, әһәмиятлерәк өлешләрен сайлап ала;

– укучыларны үткәреләчәк тәҗрибәләргә, лаборатор эш әзерләүгә тарта;

– ныгыту, кабатлау, өйгә бирелгән эшләрне үтәү өчен, дәрестә һәм өйдә эшләгәндә китәчәк вакытны исәпкә алу максаты белән, күнегүләрне алдан эшләп карый;

– дәрестә файдаланылачак укыту-методик әдәбиятны сайлап куя, кирәкле урынны тиз табу өчен, ал арны билге-күрсәткечләр белән тәэмин итә һ. б.

Эшне алдан оештырганда, укытучы дәрес планына берникадәр төзәтмәләр кертә, аны детальләштерә яки укучыларда кыенлык тудыра торган кайбер биремнәрне төшереп калдыра ала.

Дәрестә укытуны дөрес оештыру, беренчедән, педагогның үз эшчәнлеген оештыруны һәм, икенчедән, уку материалын үзләштерү, укуны стимуллаштыру өчен балалар эшен оештыруны таләп итә.

Укучылар эшчәнлеген оештыру түбәндәге укыту бурычларын куя:

– бу бурычларны кабул иткәндә, укучыларга уңайлы шартлар тудыру;

– практик эшләрне оештырганда, укучылар арасындагы функцияләрне ачык итеп бүлү;

– алдагы эшчәнлекнең ысуллары турында аларга кыска һәм аңлаешлы күрсәтмәләр бирү;

– уку биремнәрен үтәгәндә укучыларга үз вакытында ярдәм күрсәтү.

Кызганычка каршы, күп очракта укытучының дәресне оештыру функциясе бурычның куелышына гына кайтып кала һәм соңыннан аларның үтәлешенә нык контрольлек итүгә күчә. Күрсәтмә бирү, ярдәм итү, үзара тиешле ярдәм оештыру этаплары еш кына күз уңыннан төшеп кала, шулай укуның нәтиҗәлелеге кими.

Укытуның төрле төрләрендә – аңлатмалы-иллюстратив (күрсәтмәле), проблемалы, программалаштырылган һ.б. – укыту эшчәнлеген оештыруның үзенчәлекләрен карыйк.

Укыту процессында укучыларның активлыгын арттырмыйча (стимуллаштырмыйча) уңышлы укыту турында уйларга да ярамый. Стимуллаштыру компонентының оештыру артыннан килүе мәҗбүри түгел. Ул аның алдыннан килергә дә, бергә тормышка ашырылырга да мөмкин, шулай ук аны тәмамлый да ала.

Педагогика тарафыннан актив уку эшчәнлеген стимуллаштыруның күпсанлы алым һәм ысуллары тупланган, махсус методлары эшләнгән. Стимуллаштыру укучыларның игътибарын темага юнәлтү, алар да белемгә омтылыш уяту, кызыксыну, танып белүгә ихтыяҗ тудыру бурычларын үти. Бер

үк вакытта укучыларда активлаштыручы хисләр – бурыч һәм җаваплылык кебек хисләрне дә үстерү мөһим. Дәрес башында ук теманың әһәмиятен һәм гадәти булмавын ачып биреп, теманы үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру гына җитми, башка алымнарны да уйларга кирәк. Ул алымнар дәрес барышында, бигрәк тә дәреснең икенче өлешендә, кулланылырга тиеш, чөнки бу вакытта укучылар инде арыйлар һәм нинди дә булса стимулга мохтаҗ булалар. Бу киеренкелекне бетерә һәм укучыларда уку материалын актив үзләштерү теләге уята. Укытучының төп бурычы – шуңа ирешү. Укыту процессы материалны үзләштерүнең барышын агымдагы тикшерү белән тормышка ашыруны күз алдында тота. Агымдагы тикшерүгә түбәндәгеләр керә:

– укучылар эшчәнлеген күзәтү;

– бирелгән сорауларга җаваплар алу;

– гадәти һәм программалаштырылган күнегүләр эшләтү;

– дәрестәге эш вакытында аерым укучылар белән индивидуаль әңгәмәләр үткәрү;

– дәрестә, уку эше процессында, укучыларның язма эш дәфтәрләрен тикшерү.

Агымдагы тикшерү укучылар эшчәнлегендәге типик ялгышларны, кыенлыкларны ачыкларга ярдәм итә, үз вакытында аларга бөтен сыйныфның игътибарын юнәлтә, белемдә җитешсезлекләрдән, ялгыш эш-хәрәкәтләрдән кисәтә. Агымдагы тикшерү нәтиҗәсендә укытучы иң элек укучылар белән уку эшчәнлеген оештыруның үзе сайлап алган вариантының һәм шулай ук уку материалын укучыларга җиткерүнең һәм укытуның башка төрләренең рациональ файдаланылуын бәяли. Бу укытуны һәм укучыларның укуын оештыруга кирәкле төзәтмәләрне үз вакытында кертергә мөмкинлек бирә. Агымдагы тикшерү шулай ук укыту процессын өстәмә аңлатулар, ярдәмче сораулар кую һәм төгәлрәк күнегүләр бирү, планны ачыклаучы өстәмә рәсемнәр куллану, лаборатор һәм гамәли эшләрне үтәгәндә укучыларның үзара контролен һәм үзара ярдәмен оештыруны да күздә тота. Агымдагы контроль укучыларга мөнәсәбәтләрдә тактлы һәм игътибарлы булуны таләп итә.

Укыту циклы ирешелгән нәтиҗәләргә анализ ясау белән төгәлләнә. Билгеле, сүз бу очракта нәтиҗәләрнең чынбарлыкта ирешелгәннәренә анализ турында бара. Кызганычка каршы, еш кына укытуның нәтиҗәсенә анализны укучыларның дәреслек белән үзлекләреннән эшләүне оештыруга күнегүләр үтәүләренә кадәр, дәрес ахырында ук ясыйлар. Дәрес ахырында уку материалының үзләштерелүе турында без гомуми генә күзаллыйбыз. Бу һәркемгә билгеле. Монда төп игътибар яңа материалны үзләштергәндә укучыларга ярдәм оештыруга тупланырга тиеш. Икенче дәрестә инде тикшерүнең характерын һәм дәрескә анализны шактый көчәйтергә мөмкин, һәрвакыттагыча, бу очракта өйрәнелә торган теманы үзләштерүгә укучыларның әзерлек дәрәҗәсе туры килергә тиеш.

Уку материалын үзләштерүнең нәтиҗәлелегенә анализ ясаганда, укучылар белән җитәрлек күләмдә күнегүләр һәм өй эшләре үткәрелгәч, аларның факт һәм билгеләмәләрне белү дәрәҗәсен генә ачыкларга түгел, бәлки бу фактларны, билгеләмәләрне аңлап үзләштерү һәм алынган белемнәрне практик мәсьәләләр чишкәндә куллана алу-алмау дәрәҗәсенә дә игътибар итәргә кирәк. Гомуми анализ укучыларның белем һәм осталыкларындагы җитешсезлек сәбәпләрен өйрәнүне мәҗбүри кертә. Бу җитешсезлекләр укытучының укыту сыйфатына да, укучыларның тәртибенә, аларның укуга мөнәсәбәтләренә, сәламәтлекләренә, эшкә сәләтләренә, игътибарына, аларда уку эшенә күнекмәләр формалашу күләменә, китап белән эш итә белүләренә, уку һәм язу тизлегенең үсешенә дә бәйле булырга мөмкин. Укытуда ихтимал булган бөтен җитешсезлекләрне ачыклау бик әһәмиятле һәм зарур. Соңыннан инде чагыштыру юлы белән сәбәпләрне ачыкларга һәм аларны бетерүгә юнәлдерелгән чараларны билгеләргә кирәк.

### 8.6. Вопросы для самоконтроля

1. В чем сущность методологии педагогики?
2. Раскройте содержание программы педагогического исследования.
3. Назовите методы исследования.

## 8.7. Задания для практики

Охарактеризуйте и проиллюстрируйте на примерах два метода педагогического исследования.

Ознакомиться с текстом документа «Тема 8» , добавить вопросы для самоконтроля.

## 8.8. Глоссарий по теме 8

**Обучение –** целенаправленный педагогический процесс организации и стимулирования активной учебно-познавательной деятельности учащихся по овладению ЗУН (знания, умения, навыки), развитию творческих способностей и нравственных этических взглядов. Обучение – вид учебной деятельности, в которой количество и качество элементов знаний и умений ученика доводятся до должного уровня (среднего, эталонного, возможного), составляющего цель обучения.

Основанием для организации обучения является изготовленный в звене учения (и в звене обучения) продукт ученика, в котором отсутствуют необходимое качество и количество содержания, представленного в учебном материале. Если такого продукта ученика нет, то невозможно организовать и деятельность обучения.

Деятельность обучения считается завершенной, а цель ее достигнутой, если количество и качество учебного материала в повторно изготовленном продукте ученика будут соответствовать цели обучения или составлять должный уровень (средний, эталонный, возможный), представленный в цели обучения.

## 8.9. Использованные информационные ресурсы

http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор.

РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php

## Тема 9. БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕН ЯҢАРТУ

**Аннотация.** Данная тема раскрывает аксиологические основы педагогики. Рассматриваются педагогические ценности.

**Ключевые слова.** Обучение, образование, содержание, начальная школа, основная, средняя.

**Методические рекомендации по изучению темы.** Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме. После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту. В разделе Обсуждений вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### 9.1. Белем бирүнең эчтәлеген яңарту

Гомуми урта белемнең эчтәлеген яңарту – хәзерге заман мәктәбенең иң мөһим бурычларыннан берсе.

Дәүләтнең мәгариф өлкәсендәге сәясәте Татарстан Республикасының "Мәгариф турында"гы Законы нигезендә билгеләнә.

Әлеге Законның мәгариф эчтәлегенә тәэсир итә һәм аны үзгәрү кирәклегенә басым ясый торган берничә төп шартын санап үтик:

- мәҗбүри тугызъеллык белем бирү;
- белем эчтәлегендә милли һәм региональ үзенчәлекләрне истә тоту;
- белем бирү учреждениеләренең автономиялелеге һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, белем эчтәлегенең вариантлылыгы;
- белем бирү учреждениеләрен дифференцияләштерү һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, белем бирү эчтәлеген дифференцияләштерү;
- мәгариф учреждениеләренең һәр төрендә мәгариф системасының бердәмлеген һәм югары сыйфатлы гомуми урта белем бирүне тәэмин итү;
- белем эчтәлеген гуманлаштыру һәм демократияләштерү өчен шартлар тудыру;
- белем бирү стандарты.

Белем бирүнең яңа эчтәлеге күптөрле, төрле дәрәҗәле, вариантлы булуы белән аерылып тора.

Мәгариф системасын реформалау елларында республикада 217 яңа төр уку йорты (103 гимназия һәм мәктәп-гимназия, 28 эксперименталь учреждение (шуларның 12 се – балалар бакчасы); 34 лицей һәм мәктәп-лицей, 11 укыту-тәрбия комплексы, 6 колледж, 9 автор мәктәбе һәм хосусый мәктәп исәпләнә. Кыска гына вакыт эчендә әлеге мәктәпләрдә билгеле бер тәҗрибә тупланды, иҗади эшләүче коллективлар барлыкка килде. Әмма, тикшеренү-эксперимент эшләрен нәтиҗәлерәк алып бару өчен, укыту һәм тәрбиянең эчтәлегенә үзгәрешләр кертергә, бу эшкә һәр укытучыны тартырга кирәк. Казандагы 9, 30, 102, 122, 133 нче; Чаллыдагы 26, 30, 57 нче мәктәпләр, классик лицей; Әгерҗе районының Сарсак-Омга мәктәбе; Яшел Үзәндәге 1 нче укыту-тәрбия комплексы, 10, 11, 14 нче; Бөгелмәдәге 2, 5, 6, 8, 11 нче мәктәпләр; Түбән Кама районындагы Прости фермерлар мәктәбе нәкъ менә шулай эшлиләр дә.

Укытучылар үзләренең педагогик эшчәнлегенә тәнкыйтьчел карый, укыту һәм тәрбияне төрлечә оештыра башладылар. Педагогик хезмәтнең төрле эзләнү юнәлешләре һәм үрнәкләре барлыкка килә, педагогларның специальләшүе көчәя. Укытучылар эшчәнлекнең өстенлекле өлкәләрен билгелиләр (мәсәлән, уку материалын эшкәртү, дәреснең проектын төзү, шәхес үсешен көйләү һәм аңа диагноз кую).

Байтак мәктәп коллективлары Д.Б. Эльконин, В.В. Давыдов, Л.В. Заньковның үстерелешле укыту методларын кулланалар.

Республикабызның мәгариф учреждениеләрендә түбәндәге юнәлешләр буенча педагогик эзләнүләр алып барыла:

– белем бирүнең яңа эчтәлеген булдыру;

– балаларны укыту һәм тәрбияләүнең яңа метод, алым, чара, методика, технологияләрен эшкәртү;.

– уку йортларының, белем һәм тәрбия учреждениеләренең яңа моделен төзү;

– яңа һәм иң кулай идарә структурасы, идарә системасы механизмнарын һәм педагогик кадрларның квалификациясен күтәрүнең нәтиҗәле методларын булдыру.

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтү урынлы булыр: мәктәп җитәкчеләре эзләнү-тикшеренү эшен оештыруга җаваплы карарга, аңа алдан ук әзерлек эшләре алып барырга, матди һәм методик яктан булышырга, эксперимент темасын, эчтәлеген тирәнтен өйрәнеп, аңа оста җитәкчелек итәргә, фәнни җитәкче яки консультант билгеләргә, педагогик күзәтү оештырырга, билгеле бер вакыттан соң эшкә анализ ясарга тиешләр.

Фәнни сәясәтнең нигезе буларак, без, башка эшләрдәге кебек үк, экспериментны үткәрүдә башлап йөрүче, аны җиренә җиткереп алып баручы һәм билгеле бер уңай нәтиҗәгә ирешүче талантларны хуплыйбыз.

Һәр укучының сәләтен, һәвәслеген ачыклау, аңа үзенең хәленнән килгәнчә, сәләтеңчә тырышып укырга мөмкинлек тудыру – яңа төр уку йортының төп бурычы.

Моңа ничек ирешергә?

Элеккерәк елларда без сәләтле һәм аеруча сәләтле балаларга төпле белем бирү, аларның сәләтен тулысынча ачарга шартлар тудыру турында сүз алып бармый идек. Хәзер исә бу мәсьәлә яңа төр уку йортларында гамәлгә ашырыла. Балаларга урта мәктәп курсы буенча экстерн тәртибендә имтихан тапшырырга рөхсәт ителү дә – куанычлы хәл.

Моннан бер ел элек гимназия, лицей, колледжларның югары уку йортлары белән элемтәсен урнаштыру, фәнни җитәкче булдыру мәсьәләсе безне бик нык борчый иде. Бүгенге көндә һәр яңа төр уку йорты һәм югары уку йортлары үзара хезмәттәшлек итә дип әйтә алабыз.

Әлеге хезмәттәшлек үз алдына мондый бурычлар куя:

– белем бирүне кызыклы итеп оештыру;

– укучыларны югары уку йортына керергә әзерләү, шуның белән бергә, әзерлекле, белемгә омтылучы, конструкцияләү, модельләштерү белән кызыксынучы студентлар булдыру.

Лицей, гимназия укытучылары иҗади эшләүчеләрнең тәҗрибәсен өйрәнәләр, дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда яңа эш алымнары кулланалар. Казан һәм Татарстан районнары укытучыларының үзара хезмәттәшлеге дә укыту-тәрбиядә яңа алымнар кулланырга ярдәм итә. Әмма шуны да искәртәсе килә: яңа методлар эзләү белән бергә, элегрәк тупланган уңай тәҗрибәне дә онытмасак иде.

Мәктәптәге һәр укытучыга да Штейнер яки Монтессори, Заньков яки Френе методикасы нигезендә эшләргә кирәкме икән, дип уйларга нигез кала. Сәләте, акыл үсеше, психологик үзенчәлеге ягыннан бер-берсенә охшаган бала булмый. Шуңа күрә һәр шәхескә индивидуаль якын килү сорала. Белем һәм тәрбиядә һәр балага карата бер үк алымнар файдалану шәхес, акыл сәләте үсешенә каршы килә. Билгеле, яңа идея һәм методларны кулланырга кирәк. Әмма аларның конкрет шәхескә ничек йогынты ясавы турында да уйлану сорала.

Лицей ачу – әйбәт эш. Әгәр дә ул Пушкин укыган Царскосельский лицей дәрәҗәсендә булса, бигрәк тә яхшы. Алар безнең Татарстанда күпме булырга мөмкин һәм күпме кирәк? Бу турыда әйтүе кыен. Талантлы балалар өчен чын мәгънәсендәге лицейлар кирәк, әлбәттә. Ә сәләтлеләр нибары 2 процент тәшкил итә. Элмә такталарга күз салсаң, тиздән барлык мәктәпләр дә лицей булыр дигән уй туа. Уйлау сәләтенә ия булган гадәти балаларны да без талантлар рәтенә кертергә тырышабыз.

Яңа төр уку йортларына укучылар конкурс нигезендә кабул ителә. Әмма әлеге чарадан соң "сезнең малаегыз (яки кызыгыз) акыл үсеше ягыннан артта калган" дигән сүзләрне ишетеп байтак ата-ана һәм бала кайнар күз яшьләре түгә.

Конкурс турында шуны да әйтү урынлы булыр: аны кем һәм ничек үткәрә? Кыскасы, баланың сәләтен төгәл билгеләү методикасы бер илдә дә юк әле. Булганнары баланың сәләтен якынча гына билгеләргә мөмкинлек бирә.

Без IX сыйныфны тәмамлаган яшүсмерләрне "урамга чыгарып ташлыйбыз". Шушы гамәлебез белән аларга җинаять өчен юл ачабыз, һич тә

гафу ителмәслек әлеге эшебезне: "Алар укырга теләми", - дип аклыйбыз. Ләкин шуны таныйк: яшүсмерләрнең җинаять юлына басуында дәүләт, мәктәп һәм укытучылар да гаепле. Урам карамагына тапшырганчы, унбиш яшьлек үсмерләргә эшләү өчен яңа эш урыннары булдыру, һөнәри сәләт, зәвыкларын билгеләргә ярдәм итү турында уйларга иде.

Мәктәпне ташларга мәҗбүр булган егетне 2-3 елдан, төрмәгә эләкмәсә, армиягә алалар. Без, өлкәннәр, аннан Ватанны саклау дигән изге бурычны үтәвен таләп итә алабызмы соң? Ә бит шул ук Ватан аны белем алу хокукыннан мәхрүм итә.

Барлык укучылар да педагогик яклансын, үзләренең сәләт һәм мөмкинлекләренә карап белем алсын. Без шуңа ирешергә омтылыйк.

Хәзерге чорда мәктәп тәмамлаучы һәр егет һәм кыз сәламәт, актив эшчәнлеккә әзер булсын. Аларның сәламәтлеге – дәүләт байлыгы, икътисади көч, җәмгыять үсешен тәэмин итүче.

Сәламәт кешенең акылы да сәламәт, ди халык. Әмма бүгенге көндә без сәламәт балалар үстерәбез дип мактана алмыйбыз. Моннан тыш, укыту-тәрбия эшләре дә тиешле дәрәҗәдә оештырылмый. Моны республика олимпиада нәтиҗәләре дә бик ачык күрсәтә.

Эшне яхшырту өчен, яңа төр уку йортлары алдында мондый мөһим бурычлар тора:

– эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенә билгеле бер вакыттан соң ясала торган нәтиҗәләрне өйрәнүне дәвам итү;

– фәнни-методик эшнең эчтәлеген системалаштыру, нәшер итү өчен материаллар әзерләү;

– укыту планнарына үзгәрешләр кертү;

– балаларны, педагогик кадрларны сайлап алу методикасының төрле вариантларын булдыру;

– нәтиҗәләрне алдан фаразлау методикасын эшләү.

Мәгълүм ки, бу бурычларны үтәү өчен мәктәп җитәкчеләре билгеле бер социаль белем һәм күнекмәләргә ия булырга, аларга бу юнәлештә Мәгариф

хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институты, Махсус урта белем бирү фәнни-тикшеренү институты, шулай ук башка югары уку йортлары ярдәм итәргә тиеш.

Балаларның сәламәтлеге һәм гармонияле үсеше турында кайгырту һәр балага белем бирү өчен тиешле шартлар тудыруны күздә тота. Шул максаттан коррекция класслары ачыла. Аларга балаларны, тестлар кулланып, логопед һәм психолог кабул итә. Бу эш барышында, мәктәптә белем алырга ни дәрәҗәдә әзерлекле булуын һәм гомуми үсеш дәрәҗәсен ачыклау өчен, һәр бала белән индивидуаль эш үткәрелә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: әлеге классларга кабул ителүчеләр – гадәти балалар, алар яшьтәшләреннән бер яклары белән дә аерылып тормыйлар, бары тик теге яки бу сәбәп белән программа материалын әкренрәк үзләштерәләр. Мондыйларга укытучы, логопед, психолог аеруча игътибарлы булырга тиеш. Шушы таләпләр үтәлгәндә, балалар уку материалын уңышлы үзләштерәләр. Билгеле, әлеге класста эшләү өчен укытучы сайлап алу да, балалар саны да (алар 9-12 булса кулайрак) зур әһәмияткә ия.

Ә хәзер кыскача гына төп өч блок (башлангыч мәктәп, гуманитар фәннәр, табигать фәннәре) буенча белем эчтәлегенең торышына һәм үсеш перспективасына тукталыйк.

**1. Башлангыч мәктәп** программалары үзләренең эчтәлеге белән башлангыч белемнең билгеле бер максатын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән.

Соңгы елларда Татарстан мәктәпләрендә чит ил телен башлангычларда укыту, атнага биш көн укыту, укытуны интегральләштерү буенча тәҗрибә-эксперимент эшләре алып барыла. Әмма укытучы мондый эзләнү-тикшеренү эшләренә әзер түгел. Галим-методистлар да тиешле ярдәм күрсәтә алмыйлар, алар күп еллар дәвамында барлыкка килгән укыту системасына яңа курслар, программалар тәкъдим итәргә әзер түгел. Нәтиҗәдә башлангыч мәктәпне тәмамлаучыларның алга таба белем алуга әзерлек дәрәҗәсе түбәнәя баруы күзәтелә.

Хәзерге вакытта башлангыч мәктәпнең үсеш юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– акыл сәләтен үстерүгә ярдәм итә торган укыту системалары булдыру;

– гамәлдәге проблемаларның эчтәлеген яңарту.

Соңгы елларда элеккеге бертөрле стабиль программалар яңалары белән алыштырылды, аларны күчеш программалары дип тә атарга була.

**2. Гуманитар цикл фәннәре** программалары вариантлы булулары, төзелешләре белән аерылып тора. Яңа программалар нигезендә дәреслекләр, уку-укыту ярдәмлекләре, факультатив курс программалары төзелә.

Тарих курсын да үзгәртеп кору күздә тотыла, ягъни ул төп (тугызъеллык) мәктәптә өйрәнеп тәмамланырга тиеш (бу эш өч ел эчендә гамәлгә ашырылачак), шулай ук төп мәктәптә хокукый һәм җәмгыять белеменнән кайбер мәгълүматлар биреләчәк.

Гуманитар белемнең эчтәлеген яңарту аның максат һәм бурычларын яңадан билгеләү белән бәйле. Алар әхлакый һәм эстетик тәрбия бирүдә буыннар туплаган тәҗрибәне яшьләрне тәрбияләүдә куллануда, башка халыклар мәдәниятен аңларга сәләтле милли үзаңлы шәхес үстерүдән, дөньяга хисси-кыйммәти мөнәсәбәт тәрбияләүдән, укучыларда образлы фикерләү сәләте булдырудан гыйбарәт.

**3. Бүген без табигать-математика фәннәреннән** белем бирүдә "Мәгариф турында"гы Законда күрсәтелгән таләпләрне шактый уңышлы үтибез. Моны шундый факт та раслый: эти-әниләре белән бергә алга киткән капиталистик илләргә күчкән балалар андагы мәктәпләрдә дә табигать-математика фәннәрен чагыштырмача җиңел үзләштерәләр һәм абруйлы югары уку йортларына укырга керәләр.

Безнең укучылар математика, табигать белеме, география фәннәреннән белем дәрәҗәләре буенча дөньяда бишенче урында. (Бары тик Көньяк Корея, Тайвань, Швейцария, Венгриядән генә калышабыз).

Чит ил белгечләре һәрвакыт безнең галим укытучылар төзегән математика, физика, химия программалары белән кызыксынып торалар. Моңа кадәр һәр мәктәбе, һәр укытучысы үзе иҗат иткән программа нигезендә эшләгән Англиядә безнең программаларны кулланып "Белем дәрәҗәсенә таләпләр"

("Белем стандартлары") төзи башлаганнар. Халыкара Бакалавриат институты программасы без төзегән программалардан күпкә калыша.

Белем стандарты турында берничә сүз. Белем бирүнең яңа эчтәлеген булдыру гади мәсьәлә түгел. Хәзерге вакытта һәр гомуми белем бирү учреждениесенең эш юнәлешен ирекле гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырылырга тиеш. Ул вакытта белем бирү процессы дәүләт белем стандартлары аша идарә ителә. Дәүләт белем стандартлары системасын гамәлгә ашыра барып, Мәгариф министрлыгы белем алу процессында шәхесне яклау һәм кешегә база белеме алуны гарантияләү максатын куя. Дәүләт белем стандартын куллану төрле төр мәктәпләрдә алынган белемнең бер дәрәҗәдә булуын тәэмин итә, бердәм белем системасы булдырырга ярдәм итә.

## 9.2. Вопросы для самоконтроля

1. Современные аспекты обновления содержания школьного образования.
2. Дайте определение педагогических ценностей.
3. В чем суть гуманистической философии образования?

## 9.3. Задания для практики

Подготовьте схему «Классификация педагогических ценностей» и дайте их характеристику.

Ознакомиться с текстом документа «Тема 9» , добавить вопросы для самоконтроля.

## 9.4. Глоссарий по теме 9

**Аспект** (от лат. *aspectus* – вид, облик, взгляд, точка зрения) – одна из сторон рассматриваемого объекта, то, как он видится с определённой точки зрения.

**Педагогические ценности –** нормы, регламентирующие педагогическую деятельность и выступающие как познавательно-действующая система, которая служит опосредующим и связующим звеном между сложившимся общественным мировоззрением в области образования и деятельностью педагога.

## 9.5. Использованные информационные ресурсы


http://www.pedlib.ru/Books/2/0280/2_0280-65.shtml

Харламов, Иван Федорович. Педагогика: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по пед. спец. / И.Ф.Харламов. - 4-е изд., перераб. и доп.. - М.: Гардарики, 1999. – 517 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000115456_con.pdf

Психология и педагогика: учебник для вузов / [Вульфов Б.З., Иванов В.Д., Куканова Е.В. и др.]; под ред. заслуж. деят. науки Рос. Федерации, чл.-кор. РАО, д.п.н., проф. П.И. Пидкасистого. - Москва: Юрайт: Высшее образование, 2010. - 714 с. - http://z3950.ksu.ru/bcover/0000683385_con.pdf

http://do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7%E2%80%8E

http://vaniorolap.narod.ru/theme2.html

http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Pedagog/slast/07.php